**СОВЕТ НИКОЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЛАИШЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422627 с. Никольский,
ул. Центральная, д.35
тел: 4-31-44

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ**

422627 Никольский авылы,
Үзәк урамы, 35 нчы йорт,
тел: 4-31-44

2023 елның 21 декабре 79/1 номер

КАРАР

**«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итү турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы һәм 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында»гы Федераль законнар, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Никольский авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1.«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставын кабул итәргә (кушымта).

2.Әлеге карарны, законнарда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве үткәрү өчен, юстиция органына җибәрергә.

3.Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 44 маддәсендәге 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә дип билгеләргә.

– Түбәндәге карарларны үз көчен югалткан дип танырга:

– – – *Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советының 2017 елның 08 декабрендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы» 24 нче карары;*

*– Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советының 2018 елның 20 июлендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы 16 нчы карары;*

*– Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы 19 нчы карары;*

*– Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советының 2020 елның 23 мартындагы «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында»гы 6 нчы карары;*

*– Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге Советының 2021 елның 27 октябрендәге «“Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольский авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»гы 51 нче карары.*

.

5. Әлеге карарны һәм аңа кушымтаны махсус мәгълүмат стендларында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru.веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп баруны Никольский авыл җирлеге Советы рәисе — җирлек башлыгы А.Н.Пашагинга йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы
Никольский авыл җирлеге Советы рәисе —
җирлек башлыгы **А.Н.Пашагин**

***Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы***
***Никольский авыл җирлеге Советының***

***2023 елның 21 декабрендәге 79/1 нче карарына кушымта***

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «НИКОЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ УСТАВЫ

## I Бүлек. ГОМУМИ НИГЕЗЛӘМӘЛӘР

### 1 статья. Муниципаль берәмлекнең атамасы һәм хокукый статусы

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге муниципаль берәмлегенә авыл җирлеге статусы бирелгән.
2. Муниципаль берәмлекнең рәсми атамасы — «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Никольский авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге (алга таба текст буенча — авыл җирлеге).
3. Никольский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Татарстан Республикасының Лаеш муниципаль районы составына керә.

### 2 статья. Авыл җирлегенең территориаль төзелеше

1. ***Җирлек территориясе составына Никольский авылы, Кунтечи авылы, Тарлаши авылы, Сапуголи авылы, Пиголи авылы, Новая Поляна авылы, Беляково авылы торак пунктлары керә.***

***2. Җирлекнең административ үзәге булып Никольский авылы тора.***

3.Авыл җирлеге чикләре "Лаеш муниципаль районы" муниципаль берәмлеге һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән.

4.Авыл җирлеге территориясе составына, милек формаларына һәм максатчан билгеләнешенә карамастан, бөтен җирләр керә.

5.Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы законы белән гамәлгә ашырыла.

**3 статья. Гражданнарның авыл җирлегендә җирле үзидарәне гамәлгә ашыруга хокукы**

1. Авыл җирлегендә җирле үзидарә РФ гражданнары тарафыннан җирле референдумнарда, муниципаль сайлауларда һәм үз ихтыярыңны турыдан-туры белдерүнең башка формаларында катнашу аша, шулай ук әлеге Уставта күздә тотылган сайлап куела торган һәм башка җирле үзидарә органнары аша гамәлгә ашырыла.
2. Гражданнар, җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи гәүдәләнешенә (дәрәҗәсенә), дингә мөнәсәбәтенә, инанмаларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына карамастан, җирле үзидарәне турыдан-туры да, үз вәкилләре аша да гамәлгә ашыруга тигез хокукка ия.
   Авыл җирлеге территориясендә даими яисә күбрәк яшәүче чит ил гражданнары, җирле үзидарәне гамәлгә ашырганда, РФ халыкара шартнамәләренә һәм федераль законнарына ярашлы хокукларга ия булалар.
3. Гражданнар авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларына турыдан-туры мөрәҗәгать итәргә, җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында мәгълүмат алырга хокуклы.
4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, әгәр закон белән башкасы күздә тотылмаган булса, һәркемгә аның хокукларына һәм ирекләренә турыдан-туры кагылышлы документлар һәм материаллар белән танышу мөмкинлеген, шулай ук гражданнарның авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеге турында башка тулы һәм ышанычлы мәгълүмат алу мөмкинлеген тәэмин итәргә бурычлы.
5. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары гаммәви мәгълүмат чаралары аша һәм башка ысул белән гражданнарны авыл җирлеге һәм аның аерым территорияләре үсешенең иң мөһим мәсьәләләре, гомуми файдаланудагы транспорт, торак-коммуналь хуҗалык эше, халыкка төрле хезмәтләр күрсәтүче социаль-культур һәм башка учреждениеләр һәм хезмәтләр челтәре үсеше, социаль ташламалар, җәмәгать тәртибен саклау торышы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр турында даими рәвештә мәгълүматландырып торалар.
6. Гражданнар, оешмалар, әгәр үз хокуклары һәм ирекләре бозылган дип санасалар, җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының карарларына, гамәлләренә (гамәлсезлегенә) судта шикаять белдерергә хокуклы.

**4 статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасы**

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасына түбәндәгеләр керә: Никольский авыл җирлеге Советы, Никольский авыл җирлеге башлыгы, Никольский авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм әлеге Уставка ярашлы оештырыла торган башка органнар.
2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртү әлеге Уставка үзгәрешләр кертү юлы белән гамәлгә ашырыла.

**5 статья. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре**

1. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә түбәндәгеләр карый:

1. *авыл җирлеге бюджеты проектын төзү һәм карау, авыл җирлеге бюджетын раслау һәм үтәү, аның үтәлешен тикшереп бару, авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы хисапны төзү һәм раслау;*
2. *авыл җирлегенең җирле салымнарын һәм җыемнарын билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару;*
3. *авыл җирлегенең муниципаль милкәтендә булган мөлкәткә ия булу, аннан файдалану һәм аңа эш итү;*
4. *авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә беренчел янгын куркынычсызлыгы чараларын тәэмин итү;*
5. *авыл җирлеге халкына элемтә, җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру;*
6. *авыл җирлеге халкының ялын оештыру һәм аларны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру;*
7. *авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм гаммәви спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү, авыл җирлегенең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын уздыруны оештыру;*
8. *авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыру;*

9. *9җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашыру (аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен үтәү тора), әлеге кагыйдәләргә ярашлы рәвештә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;*
10. *адреслау объектларына адреслар билгеләү, адресларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, авыл җирлеге чикләрендә урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларын, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын исәпкә алмыйча) атамалар, планлаштыру структурасы элементларына атамалар бирү, мондый атамаларны үзгәртү, гамәлдән чыгару, дәүләт адрес реестрына мәгълүмат урнаштыру;*

11. *авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерүгә ярдәм итү, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыру;*
12. *балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм кануни мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләү һәм гамәлгә ашыру, җирлектә яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мониторингын оештыру һәм гамәлгә ашыру;*
13. *җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтү, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыру;*
14. *каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым-аерым туплау) һәм ташу буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;*
15. *ритуал хезмәтләрен оештыру һәм җирләү урыннарын карап тору (асрау);*
16. *Россия Федерациясе закон бирүчелеге белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны агызуны, халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыру;*
17. *авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;*
18. *милләтара һәм конфессияара килешүне ныгытуга, авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларның социаль һәм мәдәни адаптациясенә, милләтара (этнослара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен шартлар тудыру;*
19. *авыл җирлеге халкының гаммәви ялы өчен шартлар тудыру һәм халыкның гаммәви ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр буе полосаларына иркле керүен тәэмин итү;*
20. *Россия Федерациясенең гражданлык законнарына ярашлы рәвештә үз белдегең белән салынган корылманы сүтү турында карар, үз белдегең белән салынган корылманы сүтү яисә аны җир аннан файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре, территорияне планлаштыру документациясе белән билгеләнгән рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларына, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүгә яисә федераль законнар белән билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына мәҗбүри таләпләргә ярашлы хәлгә китерү турында карар кабул итү.*

2. Федераль законнар нигезендә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары, Россия Федерациясенең Бюджет кодексы ярашлы рәвештә авыл җирлеге бюджетыннан муниципаль район бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбенә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү буенча үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны ТР Лаеш муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тапшыру турында килешүләр төзергә хокуклы.

**6 статья. Авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә карыймый торган мәсьәләләрне чишүгә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының хокуклары**

1. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары түбәндәгеләргә хокуклы:
    - авыл җирлеге музейларын булдыру;
    - авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда күздә тотылган нотариаль гамәлләрне кылу;
    - опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнашу;
    - авыл җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыру белән бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыру;
    - Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм авыл җирлеге территориясендә милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга ярдәм күрсәтү;
    - авыл җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү буенча чараларны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;
    - муниципаль янгыннан саклау хезмәтен булдыру;
    - туризмны үстерү өчен шартлар тудыру;
    - кеше хокукларын тәэмин итүне җәмәгатьчелек тарафыннан контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы җәмәгать күзәтчелек комиссияләренә ярдәм күрсәтү һәм мәҗбүри тоту урыннарындагы затларга булышлык итү;
    - «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә инвалидларның иҗтимагый берләшмәләренә, шулай ук бөтенроссия инвалидлар иҗтимагый берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтү;
    - торак законнары нигезендә гражданнарга социаль билгеләнештәге торак фондының торак бүлмәләрен яллау шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак бүлмәләр бирү;
    - хуҗалары булмаган хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыру;
    - алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерткеч халәтендә булган затларга ярдәм күрсәтү буенча чаралар гамәлгә ашыру;

- участок полиция вәкаләтлесе вазыйфасын биләп торучы хезмәткәргә һәм аның гаилә әгъзаларына, әлеге хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга, торак бүлмә бирү;
- «Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-I номерлы Россия Федерациясе Законында күздә тотылган кулланучылар хокукларын яклау буенча чаралар гамәлгә ашыру;
- «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында»гы Федераль законда күздә тотылган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендәге чараларны гамәлгә ашыру;
- инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтү.

2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләрне чишәргә, башка дәүләт вәкаләтләрен («Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясына ярашлы рәвештә аларга тапшырылмаган вәкаләтләрне) гамәлгә ашыруда катнашырга хокуклы, әгәр бу катнашу федераль законнарда күздә тотылган булса, шулай ук, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертларны һәм өстәмә отчисление нормативлары буенча салым керемнәре керемнәрен исәпкә алмыйча, авыл җирлеге бюджеты керемнәре исәбенә, башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән һәм федераль законнар яисә Татарстан Республикасы законнары белән аларның компетенциясеннән чыгарылмаган башка мәсьәләләрне чишәргә хокуклы.

## 7 статья. Авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы

Авыл җирлегенең муниципальара хезмәттәшлектә катнашуы җирле үзидарә турындагы федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

## 8 статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре

Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының дәүләт хакимияте органнары белән үзара мөнәсәбәтләре түбәндәгеләр аша гамәлгә ашырыла:

1. авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының авыл җирлеген социаль-икътисади үстерүгә юнәлдерелгән дәүләт программаларын тормышка ашыруда катнашуы;
2. авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары белән дәүләт хакимияте органнары арасында шартнамәләр (килешүләр) төзү;
3. даими яисә вакытлыча эшләүче координация, консультация, киңәшмә һәм башка эшче органнар булдыру;
4. авыл җирлеге Советының Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару инициативасы;
5. законнар белән билгеләнгән үзара хезмәттәшлекнең башка формалары.

### 9 статья. Авыл җирлегенең муниципаль хезмәтен хокукый көйләү

Авыл җирлегендә муниципаль хезмәтне хокукый көйләү, шул исәптән муниципаль хезмәт вазыйфаларына таләпләр, муниципаль хезмәткәр статусын билгеләү, муниципаль хезмәтне үтү шартлары һәм тәртибе «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Муниципаль хезмәт турында» 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Кодексы һәм авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары белән гамәлгә ашырыла.

### 10 статья. Авыл җирлегенең муниципаль контроле

1. Җирле үзидарә органнары җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча кабул ителгән муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен муниципаль контрольдә тотуны оештыралар һәм гамәлгә ашыралар, ә контрольлекнең тиешле төрләре федераль законнар белән җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән очракларда, шулай ук федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен муниципаль контрольдә тотуны оештыралар һәм гамәлгә ашыралар.
2. Муниципаль контроль төрләрен оештыру һәм гамәлгә ашыру «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (назыяры) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнә.

## II Бүлек. ХАЛЫК ТАРАФЫННАН ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ТУРЫДАН-ТУРЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ ҺӘМ ХАЛЫКНЫҢ ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕ ГАМӘЛГӘ АШЫРУДА КАТНАШУ ФОРМАЛАРЫ

**11 статья. Халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның авыл җирлегендә җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формалары**

Авыл җирлеге халкы җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыра һәм җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда түбәндәге формаларда катнаша:

1. җирле референдум;
2. муниципаль сайлаулар;
3. депутатны, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи затын чакыртып алу буенча тавыш бирү;
4. авыл җирлеге чикләрен үзгәртү һәм аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү;
5. гражданнарның хокукый (хокук иҗаты) инициативасы;
6. территориаль җәмәгать үзидарәсе;
7. ачык тыңлаулар;
8. гражданнар җыены;
9. гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы);
10. гражданнар сходы;
11. гражданнардан соров алу (сораштыру);
12. гражданнарның җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре;
13. җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләрне халык булып фикер алышу;
14. Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формалар.

**12 статья. Авыл җирлегенең җирле референдумы**

1. Җирле референдум, федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры халык тарафыннан чишү максатыннан үткәрелә.
2. Җирле референдум авыл җирлегенең бөтен территориясендә «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылган үзенчәлекләрне исәпкә алып, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә».
   Гражданнарның җирле референдумда катнашу хокуклары гарантияләре, шулай ук җирле референдумны әзерләү һәм үткәрү тәртибе федераль закон һәм «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнә.
3. Җирле референдумда яшәү урыннары авыл җирлеге чикләрендә урнашкан Россия Федерациясе гражданнары катнашырга хокуклы. Россия Федерациясе

гражданнары җирле референдумда яшерен тавыш бирү аша гомуми, тигез һәм турыдан-туры үз ихтыярыңны белдерү нигезендә катнашалар.

4. Җирле референдумны үткәрү турындагы карар авыл җирлеге Советы тарафыннан түбәндәгеләрнең инициативасы буенча кабул ителә:
***1. җирле референдумда катнашу хокукына ия булган гражданнарның;***
***2. уставларында сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда катнашу күздә тотылган һәм федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда теркәлгән сайлау берләшмәсенең, башка иҗтимагый берләшмәнең;***
***3. авыл җирлеге Советының һәм авыл җирлеге Башлыгының бергәләп чыгарылган инициативасы буенча.***

5. Гражданнар, әлеге статьяның 4 нче өлешенең 2 нче пунктында күрсәтелгән сайлау берләшмәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр инициативасы буенча җирле референдум билгеләүнең шарты булып әлеге инициативаны яклап имзалар җыю тора, аларның саны район территориясендә теркәлгән референдумда катнашучылар санының биш процентын тәшкил итәргә тиеш, әмма 25 имзадан ким булырга алмый.
6. Авыл җирлеге Советы һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан бергәләп чыгарылган референдум үткәрү инициативасы авыл җирлеге Советы карары һәм авыл җирлеге Башлыгы карары (постановлениесе) белән рәсмиләштерелә.
7. Авыл җирлеге Советы җирле референдумны, авыл җирлеге Советына җирле референдум үткәрү инициативасын чыгару турындагы документлар килгән көннән башлап 30 көн эчендә билгели.
   Җирле референдум авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән срокларда билгеләнмәгән очракта, референдум гражданнарның, сайлау берләшмәләренең, авыл җирлеге Башлыгының, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Сайлау комиссиясенең яисә прокурорның мөрәҗәгате нигезендә суд тарафыннан билгеләнә. Суд тарафыннан билгеләнгән җирле референдум муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча Сайлау комиссиясе тарафыннан оештырыла, ә аны үткәрүне тәэмин итү Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы яисә судка җирле референдум үткәрүне тәэмин итү йөкләнгән башка орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

8. Тавыш бирү йомгаклары һәм җирле референдумда кабул ителгән карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.
9. Җирле референдумда кабул ителгән карар авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш һәм ул нинди дә булса дәүләт хакимияте органнары, аларның вазыйфаи затлары яисә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан раслауга мохтаҗ түгел.

10. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары җирле референдумда кабул ителгән карарның үтәлешен, әлеге Устав белән билгеләнгән алар арасындагы вәкаләтләрне бүлешүгә ярашлы рәвештә, тәэмин итәләр.
11. Җирле референдум үткәрү турындагы карар, шулай ук җирле референдумда кабул ителгән карар өстеннән гражданнар, җирле үзидарә органнары, прокурор, федераль закон белән вәкаләтле дәүләт хакимияте органнары тарафыннан суд тәртибендә шикаять бирелергә мөмкин.

## 13 статья. Авыл җирлегендә муниципаль сайлаулар

1. Авыл җирлегендә муниципаль сайлаулар, яшерен тавыш бирү аша гомуми, тигез һәм турыдан-туры сайлау хокукы нигезендә, авыл җирлеге Советы депутатларын сайлау максатыннан үткәрелә.
2. Сайлау көненә 18 яше тулган һәм сайлау хокукына ия булган Россия Федерациясе гражданы авыл җирлеге Советы депутаты итеп сайлана ала.
3. Муниципаль сайлаулар авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә. Муниципаль сайлауларны билгеләү турындагы карар сайлау көненә кадәр 90 көннән дә иртәрәк һәм 80 көннән дә соңга калмыйча кабул ителергә тиеш. Күрсәтелгән карар, ул кабул ителгән көннән башлап 5 көннән дә соңга калмыйча, гаммәви мәгълүмат чараларында рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.
   Вакытыннан алда сайлаулар билгеләнгән очракта, әлеге статьяда күрсәтелгән сроклар кыскартылырга мөмкин, әмма бер өлештән (өчтән бер өлешеннән) дә ким булмаска тиеш.

   Федераль законнарда, Татарстан Республикасы Сайлау кодексында билгеләнгән очракта, муниципаль сайлаулар муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

4. Муниципаль сайлауларны әзерләү һәм үткәрү, үз компетенцияләре чикләрендә, сайлау комиссияләренә йөкләнә.
5. Авыл җирлеге Советы депутатларын сайлау «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән билгеләнгән тәртиптә үткәрелә.
6. Авыл җирлеге Советы депутатлары, бер сайлау округына сайлаучылар вәкиллегенең уртача нормасы нигезендә оештырыла торган, бер мандатлы сайлау округлары буенча сайланалар.
   7. Бер мандатлы сайлау округы буенча тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның иң күп тавышын җыйган теркәлгән кандидат сайланган дип таныла.

Әгәр авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларда бер мандатлы сайлау округында тавыш бирү бер кандидат буенча гына уздырылса, тавыш бирүдә катнашкан сайлаучыларның 50 проценттан да ким булмаган тавышын җыйган кандидат сайланган дип санала. Теркәлгән кандидатлар җыйган тавышлар саны тигез булган очракта, алданрак теркәлгән кандидат сайланган дип санала.

8. Авыл җирлеге Советы депутатларын сайлау нәтиҗәләре рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

## 14 статья. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү

1. Авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгы, закон һәм әлеге Устав белән билгеләнгән нигезләрдә һәм тәртиптә сайлаучылар тарафыннан чакыртып алынырга мөмкин.
2. Депутатның сайлаучылар алдындагы ышанычын шик астына куючы һәм депутатлык бурычларын яисә авыл җирлеге Башлыгы бурычларын үтәмәүдә, депутат, авыл җирлеге Башлыгы статусына сыешмый торган гамәлләр кылуда һәм Россия Федерациясе Конституциясен, Татарстан Республикасы Конституциясен, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны башкача бозуда гәүдәләнгән, суд тәртибендә расланган конкрет хокукка каршы карарлары яисә гамәлләре (гамәлсезлеге) авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу өчен нигез булып тора.
3. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү халык инициативасы буенча үткәрелә.
4. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрү инициативасын чыгару һәм аны яклап гражданнар имзаларын җыю өчен, муниципаль сайлауларда катнашу хокукына ия булган ким дигәндә 10 кешедән торган инициатив төркем оештырыла.
5. Инициатив төркем, аны теркәү турындагы гариза (ходатайство) белән, муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча Сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итә. Инициатив төркемнең гаризасында депутатны чакыртып алу өчен нигез булып торган аның конкрет хокукка каршы карары яисә гамәле (гамәлсезлеге) күрсәтелергә тиеш, шулай ук инициатив төркемнең һәр әгъзасының һәм аның исеменнән авыл җирлеге территориясендә эш итәргә вәкаләтле затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, ае, көне һәм урыны, паспортының яисә гражданның паспортын алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирелү датасы (аны биргән органның атамасы яисә коды күрсәтелеп), яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Инициатив төркемнең гаризасына әлеге төркемнең барлык әгъзалары имза куярга тиеш. Гаризага

депутатның күрсәтелгән хокукка каршы карарларын яисә гамәлләрен (гамәлсезлеген)раслаучы суд карары теркәлергә тиеш.

6. Инициатив төркемне теркәү, авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәрү инициативасын яклап имзалар җыю, җыелган имзаларны тикшерү җирле референдум үткәрү өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
7. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә һәм «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылган үзенчәлекләрне исәпкә алып, җирле референдум үткәрү өчен закон белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.
8. Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча Сайлау комиссиясе тарафыннан инициатив төркемнең гаризасын караганда, авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләгәндә, тиешле депутат үзен чакыртып алу өчен нигез буларак алга сырылган кагыйдәләр (шартлар) буенча аңлатмалар бирергә, кирәкле документларны тәкъдим итәргә хокуклы. Күрсәтелгән депутат Сайлау комиссиясе, авыл җирлеге Советы утырышлары уздырыласы көнгә кадәр ким дигәндә өч көн алдан аларны уздыру вакыты һәм урыны турында язмача белдерелергә тиеш.
9. Авыл җирлеге Советы депутаты, аны чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырылганда, сайлаучыларга үзен чакыртып алу өчен нигез буларак алга сырылган кагыйдәләр (шартлар) буенча аңлатмалар бирү максатыннан, инициатив төркем белән тигез нигезләрдә агитация алып бару хокукына ия.
10. Авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгы, әгәр аны чакыртып алу өчен тиешле сайлау округында теркәлгән сайлаучыларның яртысыннан да кем булмавы тавыш бирсә, чакыртып алынган дип санала.
11. Авыл җирлеге Советы депутатын чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.
12. Муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча Сайлау комиссиясе, чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларына рәсми рәвештә нәтиҗә ясалганнан соң 5 көнлек срокта, инициатив төркемгә, авыл җирлеге Советына һәм авыл җирлеге Советының тиешле депутатына аны чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында язмача белдерә.

**15 статья. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү**

1. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү халыкның күрсәтелгән авыл җирлеге чикләрен үзгәртүгә, аны үзгәртеп коруга ризалыгын алу максатыннан үткәрелә.
2. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү авыл җирлегенең бөтен территориясендә яисә аның территориясенең бер өлешендә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән очракларда үткәрелә.
3. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнеп үткәрелә һәм «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «"Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда күздә тотылган үзенчәлекләрне исәпкә алып, "Җирле референдум турында" 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла».
4. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү, әгәр анда авыл җирлегенең яисә авыл җирлеге өлешенең сайлау хокукына ия булган халкының яртысыннан күбрәге катнашса, узган дип санала. Әгәр күрсәтелгән чикләрне үзгәртү, үзгәртеп кору өчен тавыш бирүдә катнашкан авыл җирлеге яисә авыл җирлеге өлеше халкының яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, халыкның авыл җирлеге чикләрен үзгәртүгә, аны үзгәртеп коруга ризалыгы алынган дип санала.
5. Авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, аны үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирү йомгаклары һәм кабул ителгән карарлар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

### 16 статья. Авыл җирлеге гражданнарының хокукый инициативасы

1. Гражданнар, әлеге Устав һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртиптә, хокук чыгару инициативасына хокуклы.
2. Сайлау хокукына ия булган авыл җирлеге халкы санының ким дигәндә 3 процентын тәшкил иткән, сайлау хокукына ия булган гражданнарның инициатив төркеме хокукый инициативасы белән чыга ала.
3. Хокукый инициативасын гамәлгә ашыру максатыннан гражданнар түбәндәгеләргә хокуклы:

- хокукый инициативасын фикер алышу һәм алга сөрү буенча яшәү (эшләү) урыны буенча гражданнар җыеннарын һәм башка коллектив чараларны оештырырга һәм үткәрергә;
- хокукый инициативасын алга сөрүне яклап имзалар җыю буенча инициатив төркемнәр булдырырга;
- законнарга каршы килми торган ысуллар белән авыл җирлеге халкының имзаларын җыярга һәм хокукый инициативасын алга сөрүне яклап агитация алып барырга.

4. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары гражданнарга хокукый инициативасын гамәлгә ашыруда ярдәм күрсәтергә бурычлы.
5. Гражданнарның хокукый инициативасын тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проекты, ул кертелгән көннән башлап өч ай эчендә, әлеге Устав белән билгеләнгән компетенцияләренә ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советының ачык утырышында яисә авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.
6. Гражданнарның хокукый инициативасын тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын караганда, гражданнарның инициатив төркеме вәкилләренә үз позицияләрен бәян итү мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.
7. Гражданнарның хокукый инициативасын тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль норматив хокукый акт проектын карау процедурасы, тиешлечә, авыл җирлеге Советы Регламенты, авыл җирлеге Башлыгының норматив хокукый акты белән билгеләнә.
8. Гражданнарның хокукый инициативасын тормышка ашыру тәртибендә кертелгән муниципаль хокукый акт проектын карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән нигезле карар, язмача рәсми рәвештә, аны керткән гражданнарның инициатив төркеме игътибарына җиткерелергә тиеш.

### 17 статья. Авыл җирлегенең территориаль җәмәгать үзидарәсе

1. Авыл җирлегендә территориаль җәмәгать үзидарәсе турыдан-туры халык тарафыннан гражданнар җыеннары һәм конференцияләре уздыру аша, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарәсе органнарын булдыру аша гамәлгә ашырыла.
2. Территориаль җәмәгать үзидарәсе гражданнар яшәүче түбәндәге территорияләр чикләрендә гамәлгә ашырыла: күпфатирлы торак йорт подъезды; күпфатирлы торак йорт; торак йортлар төркеме; торак микрорайон; җирлек булып тормаган авыл торак пункты; гражданнар яшәүче башка территорияләр.
3. Территориаль җәмәгать үзидарәсе гамәлгә ашырыла торган территория чикләре, әлеге территориядә яшәүче халык тәкъдиме буенча, авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган Авыл җирлегендә территориаль җәмәгать үзидарәсе турындагы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.
4. Территориаль җәмәгать үзидарәсе гамәлгә ашырыла торган территория башка шундый ук территория составына керә алмый.
5. Территориаль җәмәгать үзидарәсе, үз уставына ярашлы рәвештә, юридик зат булырга мөмкин һәм коммерциягә карамаган оешманың оештыру-хокукый формасында дәүләт теркәве узарга тиеш.
6. **Территориаль җәмәгать үзидарәсе уставында түбәндәгеләр билгеләнә:**

1. *ул гамәлгә ашырыла торган территория;*
2. *территориаль җәмәгать үзидарәсе эшчәнлегенең максатлары, бурычлары, формалары һәм төп юнәлешләре;*
3. *территориаль җәмәгать үзидарәсе органнарын формалаштыру, аларның вәкаләтләрен туктату тәртибе, хокуклары һәм бурычлары, вәкаләтләре срогы;*
4. *карарлар кабул итү тәртибе;*
5. *мөлкәтне алу тәртибе, шулай ук күрсәтелгән мөлкәттән һәм финанс акчаларыннан файдалану һәм аларга эш итү тәртибе;*
6. *территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыруны туктату тәртибе.*
7. Территориаль җәмәгать үзидарәсе эшчәнлеге мәсьәләләре буенча гражданнар җыеннары, конференцияләре аның уставына ярашлы рәвештә чакырыла.

8. Территориаль җәмәгать үзидарәсен оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар җыены, әгәр анда тиешле территориядә яшәүче һәм уналты яше тулган халыкның ким дигәндә өчтән бер өлеше катнашса, хокуклы (кворумга ия) дип санала.
   Территориаль җәмәгать үзидарәсен оештыру һәм гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча гражданнар конференциясе, әгәр анда гражданнар җыеннарында сайланган һәм тиешле территориядә яшәүче, уналты яше тулган халыкның ким дигәндә өчтән бер өлешен тәкъдим итүче делегатларның ким дигәндә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы (кворумга ия) дип санала.

9. Территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыручы гражданнар җыенының, конференциясенең аерым вәкаләтләренә түбәндәгеләр карый:
1. *территориаль җәмәгать үзидарәсе органнары структурасын билгеләү;*
2. *территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын кабул итү, аңа үзгәрешләр кертү;*
3. *территориаль җәмәгать үзидарәсе органнарын сайлау;*
4. *территориаль җәмәгать үзидарәсе эшчәнлегенең төп юнәлешләрен билгеләү;*
5. *территориаль җәмәгать үзидарәсенең керемнәр һәм чыгымнар сметасын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;*
6. *территориаль җәмәгать үзидарәсе органнары эшчәнлеге турындагы хисапларны карау һәм раслау;*
7. *инициативалы проект буенча фикер алышу һәм аны хуплау мәсьәләсе буенча карар кабул итү.*

10. Территориаль җәмәгать үзидарәсе органнары:
1. *тиешле территориядә яшәүче халыкның мәнфәгатьләрен яклыйлар;*
2. *гражданнар җыеннарында һәм конференцияләрендә кабул ителгән карарларның үтәлешен тәэмин итәләр;*
3. *әлеге территорияне карап тору, төзекләндерү буенча хуҗалык эшчәнлеген, тиешле территориядә яшәүче гражданнарның социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә юнәлдерелгән башка хуҗалык эшчәнлеген күрсәтелгән гражданнар акчасы исәбенә дә, авыл җирлеге Башкарма комитеты белән төзелгән шартнамә нигезендә авыл җирлеге бюджеты акчаларын файдаланып та гамәлгә ашыра алалар;*

4. *җирле үзидарә органнарына (авыл җирлеге Советына, авыл җирлеге Башлыгына һәм авыл җирлеге Башкарма комитетына) муниципаль норматив хокукый актлар проектларын кертергә хокуклы, бу проектлар әлеге актларны кабул итү үз компетенцияләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.*

11. Территориаль җәмәгать үзидарәсен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибе, җирле бюджеттан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартлары һәм тәртибе әлеге Устав һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

## 18 статья. Территориаль җәмәгать үзидарәсен оештыру тәртибе

1. Территориаль җәмәгать үзидарәсен оештыру максатыннан, гражданнар яисә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары инициативасы буенча, гражданнарның инициатив төркеме төзелә. Бу төркем территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы проектын эшләүне гамәлгә ашыра һәм әлеге территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыру күздә тотылган территория чикләрендә яшәүче гражданнар җыенын чакыруны оештыра.
2. Гражданнар җыены авыл җирлегенең тиешле территориясендә территориаль җәмәгать үзидарәсен булдыру турында карар кабул итә, аның уставын кабул итә, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү белән бәйле мәсьәләләр буенча авыл җирлеге Советында гражданнар җыены исеменнән эш итәргә вәкаләтле вәкилне (вәкилләрне) билгели.
3. Территориаль җәмәгать үзидарәсе, аның уставы авыл җирлеге Советы тарафыннан теркәлгән мизгелдән башлап, оештырылган дип санала.

## 19 статья. Авыл җирлегенең территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү тәртибе

1. Территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү өчен гражданнар җыенының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) тарафыннан авыл җирлеге Башлыгына түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

*1. <u>гражданнар җыенының барлык вәкаләтле вәкилләре имзалаган территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү турындагы гариза;</u>*

*2. <u>территориаль җәмәгать үзидарәсен булдыру турында карар кабул ителгән гражданнар җыены беркетмәсе (протоколы); анда вәкаләтле вәкилләрнең һәркайсының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы, ае, көне,</u>*

*паспортының яисә гражданның паспортын алыштыручы документның сериясе, номеры һәм бирелү датасы, яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш;*

3. *территориаль җәмәгать үзидарәсе уставының ике нөхсәсе (экземплярлары).*

2. Әлеге статьяның 1 нче пунктында билгеләнгән документлардан башка бүтән документларны тәкъдим итүне таләп итүгә юл куелмый.
   Вәкаләтле вәкилгә документларның исемлеге һәм аларны алу датасы күрсәтелгән квитанция (расписка) бирелә.

3. Авыл җирлеге Башлыгы, территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү турындагы документлар килгән көннән башлап ике атналык срокта, аны алдан карауны һәм уставны теркәү яисә аны теркәүдән баш тарту турында авыл җирлеге Советы карары проектын әзерләүне оештыра.
4. Гражданнар җыенының вәкаләтле вәкилләре territorialь җәмәгать үзидарәсе уставын алдан караганда һәм авыл җирлеге Советы утырышында киңәш бирү тавышы хокукы белән катнашырга хокуклы.
5. Авыл җирлеге Советы, әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән документлар авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан алынган көннән башлап 30 көн эчендә, территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү яисә аны теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә. Уставны теркәүдән баш тарту нигезләнгән булырга тиеш.
6. Территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы нормаларының Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына, авыл җирлеге Уставына, башка муниципаль норматив хокукый актларга каршы килүе территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

7. Территориаль җәмәгать үзидарәсен булдыруның максатка ярашлы булмавына сылтап, территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәүдән баш тартуга юл куелмый.
8. Территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү мәсьәләсе буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән нигезле карар, өч көн эчендә, язмача рәсми рәвештә, гражданнар җыенының вәкаләтле вәкиле (вәкаләтле вәкилләре) игътибарына җиткерелергә тиеш.
9. Авыл җирлеге Советы тарафыннан территориаль җәмәгать үзидарәсе уставын теркәү турында карар кабул ителгән очракта, уставның теркәү турында билге куелган бер нөхсәсе гражданнар җыенының вәкаләтле вәкиленә тапшырыла, икенче нөхсәсе авыл җирлеге Советында саклана.
10. Территориаль җәмәгать үзидарәсе уставына кертелә торган үзгәрешләр әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге Советы тарафыннан теркәлергә тиеш. Күрсәтелгән үзгәрешләр теркәлгән көннән башлап үз көченә керә.

## 20 статья. Ачык тыңлаулар, җәмәгатьчелек фикер алышулары

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча муниципаль норматив хокукый актлар проектлары турында авыл җирлеге халкы катнашында фикер алышу өчен, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан ачык тыңлаулар үткәрелергә мөмкин.
2. Ачык тыңлаулар халык, Җирлек Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә.
   Халык яисә авыл җирлеге Советы инициативасы буенча үткәрелә торган ачык тыңлаулар авыл җирлеге Советы тарафыннан, ә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торганнары авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

3. Ачык тыңлауларга түбәндәгеләр чыгарылырга тиеш:

*1. муниципаль берәмлек уставы проекты, шулай ук әлеге уставны әлеге норматив хокукый актларга ярашлы хәлгә китерү максатыннан, уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы конституциясе яисә законнары кагыйдәләрен төгәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертү очракларыннан тыш, әлеге уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль норматив хокукый акт проекты;*

*2. авыл җирлеге бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турындагы хисап;*

*3. авыл җирлеген социаль-икътисади үстерү стратегиясе проекты;*

*4. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясына ярашлы рәвештә муниципаль берәмлекне үзгәртеп кору өчен тавыш бирү яисә гражданнар сходлары аша белдерелгән муниципаль берәмлек халкының ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш, авыл җирлеген үзгәртү кору турындагы мәсьәләләр.*

4. 4. Ачык тыңлаулар үткәрү турындагы карар, әгәр гамәлдәге законнарда башка срок күздә тотылмаган булса, авыл җирлегенең тиешле органы яисә вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль норматив хокукый акт проекты караласы көнгә кадәр ким дигәндә 20 көн алдан кабул ителергә тиеш.
5. Ачык тыңлаулар үткәрү, аларны уздыру вакыты һәм урыны күрсәтелгән карар һәм ачык тыңлауларга чыгарыла торган тиешле муниципаль норматив хокукый акт проекты, әгәр гамәлдәге законнарда башка срок күздә тотылмаган булса, ачык тыңлаулар уздырыласы көнгә кадәр ким дигәндә 7 көн алдан бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.
6. Ачык тыңлаулар үткәрү турындагы карар бастырып чыгарылган көннән алып аларны уздыру көненә кадәр авыл җирлеге халкы авыл җирлеге Башлыгына ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча язмача тәкъдимнәр һәм искәрмәләр, шул исәптән ачык тыңлауларга чыгарыла торган муниципаль норматив хокукый акт проектына төзәтмәләр һәм башка тәкъдимнәр җибәрергә хокуклы. Авыл җирлеге Башлыгы килеп төшкән тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне гомумиләштерүне оештыра. Күрсәтелгән тәкъдимнәр һәм искәрмәләр ачык тыңлауларда катнашучылар игътибарына җиткерелә.

7. Ачык тыңлаулар муниципаль норматив хокукый акт проекты караласы көнгә кадәр ким дигәндә 7 көн алдан үткәрелә. Ачык тыңлаулар белгечләр, экспертлар, кызыксынучы затларны чакырып уздырыла. Ачык тыңлауларда авыл җирлегендә яшәүче һәркем катнашырга хокуклы.

8. Ачык тыңлаулар уздыру нәтиҗәләре буенча тәкъдимнәр (рекомендацияләр) кабул ителә, алар ачык тыңлауларга чыгарылган муниципаль норматив хокукый акт проектын кабул итү үз компетенцияләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге вазыйфаи затлары тарафыннан мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.
9. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре, шул исәптән кабул ителгән карарларның нигезләнгән дәлилләре, әгәр гамәлдәге законнарда башка срок күздә тотылмаган булса, ачык тыңлаулар үткәрелгәннән соң 5 көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.
10. Ачык тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган норматив хокукый акт белән билгеләнә.
11. Генераль планнар проектлары, җир аннан файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тоткан проектлар, җир участогын яисә капиталь төзелеш объектын шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелешнең чик параметрларыннан тайпылырга рөхсәт бирү, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләү турындагы карарлар проектлары буенча, расланган җир аннан файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре булмаганда җир участокларының һәм капиталь төзелеш объектларының рөхсәт ителгән файдалануының бер төрен мондый файдалануның башка төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яисә ачык тыңлаулар үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар кагыйдәләрен исәпкә алып, авыл җирлеге уставы һәм (яисә) авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.

**21 статья. Авыл җирлеге гражданнар җыены**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр турында фикер алышу, халыкка җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлегенең җирле үзидарә вазыйфаи затлары эшчәнлеге турында мәгълүмат бирү, инициативалы проектлар кертү һәм аларны карау

мәсьәләләре буенча фикер алышу, авыл җирлеге территориясендә территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыру өчен гражданнар җыеннары үткәрелергә мөмкин. Гражданнар җыеннары микрорайоннар, торак массивлары, кварталлар, урамнар, торак йортлар буенча чакырыла.

2. Гражданнар җыены халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча, шулай ук территориаль җәмәгать үзидарәсе уставында күздә тотылган очракларда үткәрелә.
3. Авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар җыены, тиешлечә, авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

   Халык башлангычы (инициативасы) буенча үткәрелә торган гражданнар җыелышы — территория җирле үзидарә органнарының, тиешле территориядә яшәүче һәм җыелышта катнашырга хокукы булган халык санының 10 процентттан да ким булмаган гражданнар төркеменең, әлеге территорияләрдә урнашкан предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар җитәкчеләренең язмача тәкъдиме буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

   Гражданнар җыелышын үткәрү турындагы тәкъдимдә аның каравына чыгарыла торган мәсьәләләр исемлеге, җыелышны үткәрүнең күздә тотылган вакыты һәм урыны булырга тиеш. Тәкъдимгә вәкаләтле затлар кул куярга тиеш, әгәр җыелыш үткәрү башлангычы белән гражданнар төркеме мөрәҗәгать итсә — әлеге гражданнар тарафыннан аларның һәркайсының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган датасы, яшәү урыны адресы күрсәтелеп кул куела.

   Авыл җирлеге Советы гражданнар җыелышын үткәрү турында кертелгән тәкъдимне үзенең чираттагы (якын арадагы) утырышында карый.

   Авыл җирлеге Советы, максатка ярашлы булмау сылтавы белән, гражданнар җыелышын үткәрүдән баш тартырга хокуклы түгел.

5. Территория җирле үзидарәсен гамәлгә ашыру максатыннан гражданнар җыелышын билгеләү һәм үткәрү тәртибе территория җирле үзидарәсе уставы белән билгеләнә.
6. Гражданнар җыелышын үткәрү вакыты һәм урыны турында, шулай ук фикер алышуга кертелә торган мәсьәләләр турында тиешле территориядә яшәүчеләр җыелыш үткәрелә торган көнгә кадәр 7 көннән дә соңга калмыйча хәбәрдар ителәләр; моның өчен массакүләм мәгълүмат чаралары, почта хәбәрнамәләре, фатирларны (ишегалларын) йөреп чыгу, белдерүләр һәм мөмкин булган башка чаралар файдаланыла.

   Гражданнар җыелышын әзерләүне һәм үткәрүне авыл җирлеге Башкарма комитеты тәэмин итә.

7. Җыелышлар эшендә әлеге территориядә яшәүче, сайлау хокукына ия булган гражданнар катнашырга хокуклы. Җыелышта катнашырга хокукы булган гражданнарның гомуми саны Россия Федерациясе гражданнарының Россия Федерациясе чикләрендә килү урыны буенча һәм яшәү урыны буенча теркәү

исәбе мәгълүматлары нигезендә билгеләнә (бу мәгълүматлар муниципаль сайлаулар үткәргәндә файдаланыла).

.

8. Гражданнар җыены авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларына мөрәҗәгатьләр кабул итә ала, шулай ук авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары белән үзара мөнәсәбәтләрдә гражданнар җыены исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларны сайлый ала.
9. Территориаль җәмәгать үзидарәсен гамәлгә ашыру белән бәйле мәсьәләләр буенча үткәрелә торган гражданнар җыены территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы белән аның компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча карар кабул итә.
10. Гражданнар җыенында кабул ителгән мөрәҗәгатьләр, мөрәҗәгатьләрдәге мәсьәләләрне чишү үз компетенцияләренә кертелгән җирле үзидарә органнары һәм авыл җирлеге җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан язмача җавап җибәреп, мәҗбүри рәвештә каралырга тиеш.
11. Гражданнар җыенын билгеләү һәм үткәрү тәртибе, шулай ук гражданнар җыены вәкаләтләре федераль закон, әлеге Устав һәм авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы белән билгеләнә.
12. Гражданнар җыены йомгаклары, ул үткәрелгәннән соң бер айлык срокта, рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**22 статья. Авыл җирлеге гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы)**

1. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) җирле әһәмияттәге мәсьәләләр турында фикер алышу һәм авыл җирлегендә яшәүче барлык халык вәкилләренең фикерен ачыклау кирәк булган очракта үткәрелә. Авыл җирлегенең тиешле территориаль өлешләрендә яшәүчеләр арасыннан гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыенын чакыру кыенлашкан очракларда, шул исәптән тиешле территориядә яшәүче һәм гражданнар җыенында катнашырга хокуклы халык саны 100 кешедән артканда үткәрелә.
2. Гражданнар конференциясен (делегатлар җыелышын) билгеләү һәм үткәрү, делегатларны сайлау тәртибе әлеге Устав, авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты, территориаль җәмәгать үзидарәсе уставы белән билгеләнә.
3. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) гражданнар җыены вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.
4. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) халык, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә. Авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), тиешлечә, авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә. Халык

инициативасы буенча үткәрелә торган гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнә.

5. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы), әгәр анда гражданнар җыеннарында сайланган һәм тиешле территориядә яшәүче, уналты яше тулган халыкның ким дигәндә өчтән бер өлешен тәкъдим итүче делегатларның ким дигәндә өчтән ике өлеше катнашса, хокуклы (кворумга ия) дип санала. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) карарлары конференциядә катнашучы делегатларның күпчелек тавышы белән кабул ителә.
6. Гражданнар конференциясе (делегатлар җыелышы) йомгаклары, ул үткәрелгәннән соң бер айлык срокта, рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

**23 статья. Авыл җирлеге гражданнар сходы**

1. Гражданнар сходы халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формасы булып тора.
2. Гражданнар сходы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законда күздә тотылган очракларда һәм Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар сходына әзерлек күрү һәм аны үткәрү тәртибе турында»гы Нигезләмәгә ярашлы рәвештә үткәрелә.
3. «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында күздә тотылган очракларда гражданнар сходы түбәндәге мәсьәләләр буенча үткәрелергә мөмкин:

*1. торак пунктта, әлеге торак пункт составына кергән җирлек (муниципаль район) чикләрен үзгәртү һәм бу үзгәреш нәтиҗәсендә әлеге торак пункт территориясен башка җирлек (муниципаль район) территориясенә кертү мәсьәләсе буенча;*
*2. җирлек составына керүче торак пунктта, әлеге торак пункт территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча;*

3. *<u>авыл торак пунктында, авыл торак пункты старостасы кандидатурасын алга сөрү мәсьәләсе буенча, шулай ук авыл торак пункты старостасы вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату мәсьәләсе буенча;</u>*

4. *<u>авыл торак пунктында гражданнар сходы, шулай ук Россия Федерациясенең муниципаль хезмәт турындагы законнарында күздә тотылган очракларда, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә конкурс уздырганда конкурс комиссиясе составына кандидатлар алга сөрү максатыннан да үткәрелергә мөмкин.</u>*

4. Гражданнар сходы муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан яисә торак пунктта яшәүче, сайлау хокукына ия булган һәм ким дигәндә 10 кешедән торган гражданнар төркеме инициативасы буенча чакырылырга мөмкин.
5. Сход үткәрү инициативасын яклап җыярга кирәк булган имзалар саны әлеге торак пункт территориясендә даими яисә күбрәк яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия булган гражданнар санының 5 процентын тәшкил итәргә тиеш, әмма 25 имзадан ким булырга алмый.
6. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан чакырыла торган гражданнар сходы муниципаль берәмлек башлыгы карары (постановлениесе) белән билгеләнә, инициатив төркем тарафыннан чакырыла торган гражданнар сходы муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы карары белән билгеләнә.
7. Торак пунктта яшәүчеләр гражданнар сходы үткәреләсе вакыт һәм урын турында алдан хәбәрдар ителәләр, шулай ук «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар сходына әзерлек күрү һәм аны үткәрү тәртибе турында»гы Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә, гражданнар сходы карарына чыгарыла торган мәсьәләләр буенча муниципаль хокукый акт проекты һәм материаллар белән алдан таныштырылалар.
8. Сходта кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар булып тора, муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан имзалана һәм Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертелергә тиеш.

9. Әлеге статьяда күздә тотылган гражданнар сходы, әгәр анда торак пунктта яисә җирлектә яшәүче һәм сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан күбрәге катнашса, хокуклы (кворумга ия) дип санала. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүче һәм сайлау хокукына ия булган халыкның яртысыннан

күбрәгенең бер үк вакытта бергә катнашу мөмкинлеге булмаган очракта, гражданнар сходы, әлеге уставка ярашлы рәвештә, гражданнар сходы үткәрү турында карар кабул ителгән көннән башлап бер айдан артмаган срокта этаплап үткәрелә. Бу очракта гражданнар сходында элек катнашкан затлар алдагы этапларда тавыш бирүдә катнашмыйлар. Гражданнар сходы карары, әгәр аның өчен гражданнар сходында катнашучыларның яртысыннан күбрәге тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала;

10. Гражданнар сходы җирлек составына керүче торак пункт территориясенең бер өлешендә, әлеге торак пункт территориясенең әлеге өлешендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча үткәрелергә мөмкин.

Мондый гражданнар сходы торак пункт территориясенең тиешле өлешендә яшәүче һәм ким дигәндә 10 кешедән торган гражданнар төркеме инициативасы буенча җирлек Советы тарафыннан чакырыла.

Гражданнар сходы үткәрелә торган торак пункт территориясе чикләре, җирлек әһәмияттәге тиешле мәсьәләне чишкәндә торак пункт территориясенең күрсәтелгән өлешендә яшәүчеләр мәнфәгатьләренең гомумилеге критерийларыннан чыгып, җирлек Советы карары белән билгеләнә.

**24 статья. Авыл җирлеге гражданнарыннан сораштыру**

1. Гражданнардан сораштыру авыл җирлегенең бөтен территориясендә яисә аның территориясенең бер өлешендә халыкның фикерен ачыклау һәм җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары тарафыннан карарлар кабул иткәндә бу фикерне исәпкә алу максатыннан үткәрелә.

   Сораштыру нәтиҗәләре тәкъдим итү (рекомендация) характерында гына була.

2. Гражданнардан сораштыруда авыл җирлегенең сайлау хокукына ия булган халкы катнашырга хокуклы. Инициативалы проектны яклау буенча гражданнарның фикерен ачыклау мәсьәләсе буенча үткәрелә торган сораштыруда муниципаль берәмлекнең яисә уналты яше тулган һәм инициативалы проектны тормышка ашыру күздә тотылган аның өлешенең халкы катнашырга хокуклы.
3. Гражданнардан сораштыру түбәндәгеләрнең инициативасы буенча үткәрелә:
   - авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы инициативасы буенча — җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча;
   - Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча — республика һәм республикаара әһәмияттәге объектлар өчен авыл

жирлеге җирләренең максатчан билгеләнешен үзгәртү турында карарлар кабул иткәндә гражданнар фикерен исәпкә алу өчен;
- муниципаль берәмлекнең яисә инициативалы проектны тормышка ашыру күздә тотылган аның өлешенең уналты яше тулган халкы инициативасы буенча — әлеге инициативалы проектны яклау турында гражданнар фикерен ачыклау өчен.

4. Гражданнардан сораштыруны билгеләү һәм үткәрү тәртибе авыл җирлеге Советының норматив хокукый акты белән билгеләнә.
5. Гражданнардан сораштыруны билгеләү турындагы карар авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә. Гражданнардан сораштыру үткәрү өчен Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Лаеш муниципаль районының түбәндәге веб-адрес буенча урнашкан рәсми сайты файдаланылырга мөмкин: http://laishevo.tatarstan.ru. Авыл җирлеге Советының сораштыру билгеләү турындагы карарында түбәндәгеләр билгеләнә:
   - *сораштыру үткәрү датасы һәм сроклары;*
   - *сораштыру уздырганда тәкъдим ителә торган мәсьәләнең (мәсьәләләрнең) формулировкасы;*
   - *сораштыру үткәрү методикасы;*
   - *сораштыру бите (опросный лист) формасы;*
   - *сораштыруда катнашучы авыл җирлеге халкының минималь саны;*
   - *Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтын файдаланып гражданнардан сораштыру үткәргән очракта, сораштыруда катнашучыларның шәхесен ачыклау (идентификацияләү) тәртибе.*
6. Авыл җирлеге халкы гражданнардан сораштыру үткәрелү турында сораштыру уздырыласы көнгә кадәр ким дигәндә 10 көн алдан хәбәрдар ителә.
7. Гражданнардан сораштыруга әзерлек күрү һәм аны үткәрү белән бәйле чараларны финанслау түбәндәгеләр исәбенә гамәлгә ашырыла:
   - *авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбенә — сораштыру авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары яисә муниципаль берәмлек халкы инициативасы буенча үткәрелгәндә;*
   - *Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбенә — сораштыру Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары инициативасы буенча үткәрелгәндә.*
8. Сораштыру нәтиҗәләре, ул үткәрелгәннән соң бер айлык срокта, бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш. Сораштыру нәтиҗәләре белән авыл җирлегендә яшәүче һәркем танышырга хокуклы. Сораштыру нәтиҗәләре авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан тиешле карарлар кабул иткәндә мәҗбүри рәвештә исәпкә алынырга тиеш.

**25 статья. Авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге иң мөһим мәсьәләләрен халык булып фикер алышу**

1. Муниципаль хокукый актлар проектларын һәм җирле әһәмияттәге башка иң мөһим мәсьәләләрне халык булып фикер алышуга чыгару турындагы карар, авыл җирлеге Советы билгели торган тәртиптә, авыл җирлеге Советының үз инициативасы буенча яисә тиешле территориядә яшәүче гражданнар таләбе буенча кабул ителә.
2. Муниципаль хокукый акт проекты тексты һәм халык булып фикер алышуга чыгарыла торган мәсьәләләр буенча башка материаллар, аларны халык булып фикер алышуга чыгару турында карар кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча, гаммәви мәгълүмат чараларында бастырылып чыгарыла, авыл җирлеге халкына таратыла, халык танышу өчен үтемле булган урыннарда урнаштырыла, башка ысуллар белән халыкка җиткерелә.
3. Мәсьәләне халык булып фикер алышуга чыгару белән бер үк вакытта, авыл җирлеге Советы фикер алышу барышында килеп төшә торган тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне карау буенча эшне оештыру срогын һәм тәртибен билгели, күрсәтелгән максат өчен махсус комиссия төзи.
4. Авыл җирлеге Советы үзе чыгарган муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка иң мөһим мәсьәләләр буенча фикер алышуны тәэмин итә, моның өчен кирәкле шартлар тудыра.
5. Халык булып фикер алышуга чыгарылган мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр авыл җирлеге Советына җибәрелә.
6. Муниципаль хокукый актлар проектлары һәм җирле әһәмияттәге башка иң мөһим мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр авыл җирлеге Советы тарафыннан карала.
7. Халык булып фикер алышу йомгаклары турында халыкка мәгълүмат җиткерелә.

**26 статья. Авыл җирлегенең җәмәгать (консультатив) советлары**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча карарлар эшләү һәм аларны тормышка ашыру вакытында халыкның ихтыяҗларын һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алу, җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә җәмәгатьчелек контролен гаммәлгә ашыру максатыннан, гражданнарның һәм авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү өчен авыл җирлегенең Җәмәгать советы төзелә.
2. Авыл җирлегенең Җәмәгать советы аның эшчәнлегендә авыл җирлеге халкының, иҗтимагый берләшмәләр һәм башка коммерциягә карамаган оешмалар вәкилләренең ирекле катнашуы нигезендә формалаша.
3. Авыл җирлеге Җәмәгать советын формалаштыру тәртибе, аның вәкаләтләре, аның утырышларын уздыру һәм карарлар кабул итү тәртибе, авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының мәгълүмат бирүгә, консультацияләр уздыруга һәм авыл җирлеге Җәмәгать советы эшчәнлегенә ярдәм итүнең башка мәсьәләләренә кагылышлы хокуклары, бурычлары һәм җаваплылыгы, аны таркату

процедурасы, шулай ук аны оештыруның һәм эшчәнлегенең башка мәсьәләләре авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган нигезләмә белән билгеләнә.
4. Башка Җәмәгать (консультатив) советлары авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары каршында аларның карарларына ярашлы рәвештә төзелергә мөмкин.
5. Җәмәгать (консультатив) советларында эш җәмәгатьчелек нигезләрендә гамәлгә ашырыла.

### 27 статья. Гражданнарның авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына мөрәҗәгатьләре

1. Гражданнар авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарына шәхси һәм коллектив рәвештә мөрәҗәгать итәргә хокуклы.
2. Гражданнарның мөрәҗәгатьләре «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда каралырга тиеш.
3. Гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау тәртибен һәм срокларын бозган өчен җирле үзидарә вазыйфаи затлары Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

### 28 статья. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруның һәм анда катнашуның башка формалары

1. Федераль законнарга ярашлы рәвештә әлеге Уставта күздә тотылган халык тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашу формалары белән беррәттән, гражданнар җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Татарстан Республикасы Конституциясенә һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган башка формаларда да катнашырга хокуклы.
2. Авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыру һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуы канунлык һәм ирекле лек принципларына нигезләнә.
   Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары халыкка авыл җирлегендә яшәүчеләр тарафыннан җирле үзидарәне турыдан-туры гамәлгә ашыруда һәм халыкның җирле үзидарәне гамәлгә ашыруда катнашуында ярдәм итәргә бурычлы.

## III Бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

### 29 статья. Авыл җирлеге Советы — авыл җирлегенең җирле үзидарә вәкиллекле органы

1. Авыл җирлеге Советы — авыл җирлегенең даими эшләүче сайлап куела торган коллегиаль җирле үзидарә вәкиллекле органы.
2. Авыл җирлеге Советының рәсми атамасы — «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге Советы» (алга таба — авыл җирлеге Советы).
3. Авыл җирлеге Советының вәкаләтләр срогы — 5 ел.
4. Авыл җирлеге Советы авыл җирлегендә яшәүчеләр алдында хисаплы һәм алар тарафыннан контрольдә тотыла.
5. Авыл җирлеге Советының мөһәре, үз атамасы язылган бланклары бар.
6. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген тәэмин итү чыгымнары, Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясенә ярашлы рәвештә, авыл җирлеге бюджетында аерым юл белән күздә тотыла.

### 30 статья. Авыл җирлеге Советы составы

1. Авыл җирлеге Советы бер мандатлы сайлау округлары буенча муниципаль сайлауларда сайлана торган 10 депутаттан тора.
2. Авыл җирлеге Советы, аның составына авыл җирлеге Советының билгеләнгән санының ким дигәндә өчтән ике өлеше депутат итеп сайланган очракта, хокуклы (кворумга ия) дип санала.

### 31 статья. Авыл җирлеге Советы депутатының, җирле үзидарәнең сайлап куела торган затының, җирле үзидарәнең сайлап куела торган органы әгъзасының статусы

1. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре уку сайланган көннән башлана һәм яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы эше башланган көнне туктатыла.
2. Әлеге Уставта билгеләнгән очраклардан тыш, авыл җирлеге Советы депутаты даими булмаган нигездә эшли, депутатлык эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм вазыйфаи бурычларын үтәү белән бергә алып бара.
3. Авыл җирлеге Советы депутаты статусы белән бәйле чикләүләр федераль законнар белән билгеләнә.

4. Авыл җирлеге Советы депутатына Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына, әлеге Уставка, авыл җирлеге Советы карарларына ярашлы рәвештә үз вәкаләтләрен тоткарлыксыз гамәлгә ашыру өчен шартлар тәэмин ителә.
5. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана торган Депутатлык этикасы кагыйдәләрен үтәргә бурычлы, аларда шул исәптән депутатның түбәндәге йөкләмәләре булырга тиеш:
1. аңа шәхсән яисә аның якын туганнарына кагылышлы мәсьәләләрне чишкәндә җирле үзидарә органнары, оешмалар, вазыйфаи затлар, муниципаль хезмәткәрләр һәм гражданнар эшчәнлегенә йогынты ясау өчен депутат статусын файдаланмаска;

2. депутатлык бурычларын объектив үтәүдә шик тудырырга мөмкин булган тәртиптән тыелырга, шулай ук үзенең абруена яисә авыл җирлеге Советы авторитетына зыян китерә алган низаглы (конфликтлы) хәлләрдән качарга;
3. мәнфәгатьләр низагы — шәхси кызыксыну депутатлык бурычларын объектив үтәүгә йогынты ясаган яисә йогынты ясый алган очрак — туу куркынычы булганда, бу хакта авыл җирлеге Советына хәбәр итәргә һәм әлеге мәнфәгатьләр низагын кисәтүгә яисә җайга салуга юнәлдерелгән Совет карарын үтәргә;
4. авыл җирлеге Советында билгеләнгән гаммәви чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә;
5. депутатлык бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә үзенә мәгълүм булган, федераль закон нигезендә конфиденциаль характердагы мәгълүматларга кертелгән мәгълүматларны хәбәр итмәскә (таратмаска) һәм аларны депутатлык эшчәнлеге белән бәйле булмаган максатларда файдаланмаска;
6. депутатлык бурычларын үтәү белән бәйле рәвештә физик һәм юридик затлардан бүләкләр (акчалата бүләкләүләр, ссудалар, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнарын түләү һәм башка бүләкләр) алмаска.

6. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куела торган органы әгъзасы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәргә, бурычларны башкарырга тиеш. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм булуны, нәкъ акчаларны һәм кыйммәтлелекләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәгән, бурычларны

башкармаган очракта, әгәр «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законда башкасы күздә тотылмаган булса, депутатның, җирле үзидарәнең сайлап куела торган органы әгъзасының, җирле үзидарәнең сайлап куела торган вазыйфаи затының вәкаләтләре вакытыннан алда туктатыла.

7. Авыл җирлеге Советы депутаты тарафыннан Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнарына ярашлы рәвештә тәкъдим ителә торган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Рәисе карары буенча, Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә уздырыла.
8. «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категориядәге затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (вкладлар) ачуны һәм булуны, нәкъ акчаларны һәм кыйммәтлелекләрне саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны үтәмәү, бурычларны башкармау фактлары ачыкланганда, Татарстан Республикасы Рәисе депутатның, җирле үзидарәнең сайлап куела торган органы әгъзасының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату яисә күрсәтелгән затларга карата башка җаваплылык чарасын куллану турындагы гариза белән тиешле карар кабул итәргә вәкаләтле җирле үзидарә органына яисә судка мөрәҗәгать итә.

9. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары махсус бүлеп бирелгән биналарда, урыннарда, шулай ук ишегалды эче территорияләрендә үткәрелә, бу очрашуларны уздыру тормышны тәэмин итү объектларының, транспорт яисә социаль инфраструктураның, элемтә эшчәнлегенең бозылуына, җәяүлеләр һәм (яисә) транспорт чаралары хәрәкәтенә яисә гражданнарның торак бүлмәләренә яки транспорт яисә социаль инфраструктура объектларына керүенә тоткарлыклар тудыруга китермәскә тиеш. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына яисә җирле үзидарә органнарына мондый очрашулар турында белдерү таләп ителми. Бу очракта депутат күрсәтелгән органнарга аларны уздыру датасы һәм вакыты турында алдан мәгълүмат бирергә хокуклы.
10. Җирле үзидарә органнары депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган биналар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен билгелиләр.

11. Депутатның сайлаучылар белән гаммәви чара формасындагы очрашулары Россия Федерациясенең җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, адымнар (шествиеләр) һәм пикетлаулар турындагы законнарына ярашлы рәвештә үткәрелә.
12. Россия Федерациясенең җыеннар, митинглар, демонстрацияләр, адымнар (шествиеләр) и пикетлаулар турындагы законнары белән билгеләнә торган гаммәви чара формасында депутатның сайлаучылар белән очрашуларын оештыруга яисә үткәрүгә тоткарлык ясау Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылыкка тарту өчен нигез булып тора.

**32 статья. Авыл җирлеге Советы депутатының сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәте**

1. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар белән, шулай ук үзенең сайлау округы территориясендә урнашкан предприятие коллективлары, оешмалар, дәүләт һәм башка органнар белән элемтә тота.
2. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында җаваплы һәм аларга хисаплы.
3. Авыл җирлеге Советы депутаты сайлаучылар алдында үз эше турында елга бер тапкырдан да кем булмыйча хисап тота, даими рәвештә аларны авыл җирлеге Советы эше турында мәгълүматландырып тора, шулай ук аена бер тапкырдан да кем булмыйча сайлаучыларны кабул итүне уздыра.
4. Авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кануни хокукларын, ирекләрен һәм мәнфәгатьләрен тәэмин итү буенча законнарда күздә тотылган чараларны күрергә, шул исәптән алардан килеп төшкән тәкъдимнәрне, гаризаларны, шикаятьләрне карарга, аларда булган мәсьәләләрне дөрес һәм вакытында чишүгә булышлык итәргә бурычлы.

**33 статья. Яңа сайланган авыл җирлеге Советы эшен оештыру**

1. Яңа чакырылыш авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан ким дигәндә өчтән ике өлеше депутат итеп сайланган көннән соң, ун көннән дә соңга калмыйча үзенең беренче утырышына җыела. Сайлаулардан соң авыл җирлеге Советының беренче утырышы авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан, ә аның булмаган очрагында — муниципаль сайлауларны һәм җирле референдумны үткәрү буенча Сайлау комиссиясе тарафыннан чакырыла.
2. Сайлаулардан соң авыл җирлеге Советының беренче утырышын, яңа авыл җирлеге Башлыгы сайланганчы, авыл җирлеге Советының яшь буенча иң өлкән депутаты ача һәм алып бара.

**34 нче статья. Авыл җирлеге Советы компетенциясе**

Авыл җирлеге Советы компетенциясенә түбәндәгеләр керә:

1. авыл җирлеге Уставын кабул итү һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү;
2. законнар нигезендә авыл җирлеге территориясендә һәммәсе өчен мәҗбүри кагыйдәләр билгеләү;
3. авыл җирлеге бюджетын һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау;
4. Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнарына ярашлы рәвештә җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару, аларны түләү буенча ташламалар бирү;
5. авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору турында башлангыч (инициатива) белән чыгу;
6. авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны билгеләү һәм авыл җирлеге Советы депутатларын сайлау буенча сайлау округлары схемасын раслау;
7. җирле референдум билгеләү;
8. авыл җирлеге Башлыгын сайлау;
9. авыл җирлеге Башлыгы урынбасарын сайлау;
10. авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан муниципаль район Советына авыл җирлеге вәкилен сайлау;
11. авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасын раслау, аның хезмәткәрләренең чикке санын билгеләү;
12. авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге Советы депутатын чакырып алу буенча тавыш бирүне билгеләү;
13. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында закон чыгару башлангычы хокукын гамәлгә ашыру;
14. авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аңа эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; читкә юнәлтелүе авыл җирлеге Советы белән килешү буенча яисә ул раслаганнан соң гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәт төрләренең таләпнамәсен (переченен) билгеләү.
15. авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итү һәм аңа эш итү тәртибен, шул исәптән федераль законнар нигезендә аны хосусыйлаштыру тәртибен һәм шартларын билгеләү; читкә юнәлтелүе авыл җирлеге Советы белән килешү буенча яисә ул раслаганнан соң гамәлгә ашырыла торган муниципаль мөлкәт төрләренең таләпнамәсен (переченен) билгеләү;
16. муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзү, аларны үзгәртеп кору һәм бетерү турында карарлар кабул итү тәртибен, шулай ук, федераль законнарда күздә тотылган очракларны исәпкә алмыйча, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәтләренә, эшләрне башкаруга тарифлар билгеләү тәртибен билгеләү;

17. муниципальара хезмәттәшлек оешмаларында авыл җирлегенең катнашу тәртибен билгеләү;
18. җирле үзидарә органнары эшчәнлеген матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итү тәртибен билгеләү;
19. авыл җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү (чыгару) турында карар кабул итү;
20. авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрнең үтәлешен контрольдә тоту;
21. авыл җирлеге торак пунктларында урамнарга, мәйданнарга һәм гражданнар яши торган башка территорияләргә исемнәр бирү;
22. муниципаль махсуслаштырылган торак фондының торак бүлмәләрен бирү тәртибен билгеләү;
23. территория җирле үзидарә органнарына авыл җирлеге бюджетыннан кирәкле акчаларны бүлеп бирү шартларын һәм тәртибен билгеләү;
24. автоном коммерциягә карамаган оешмалар һәм фондлар формасында коммерциягә карамаган оешмалар төзү турында карарлар кабул итү;
25. авыл җирлеге Уставына һәм авыл җирлеге Советы карарларына аңлатма бирү;
26. авыл җирлеге Советы Регламентын һәм үз эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча башка карарлар кабул итү;
27. авыл җирлеге Советы аппараты турындагы нигезләмәне раслау;
28. авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын һәм авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын раслау, аларның таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;
29. авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;
30. авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау;
31. муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү), авыл җирлеге халкына рәсми мәгълүматны җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасын һәм (яисә) челтәр басмасын гамәлгә кую;
32. федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирлекләрнең вәкиллекле органнары карамагына кертелгән башка вәкаләтләр, шулай ук әлеге Устав белән авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән башка вәкаләтләр.

2. Совет сельского поселения заслушивает ежегодные отчеты Главы сельского поселения о результатах его деятельности, деятельности Исполнительного комитета сельского поселения и иных подведомственных Главе сельского поселения органов местного самоуправления, в том числе о решении вопросов, поставленных Советом сельского поселения.

**35 нче статья. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе**

1. Авыл җирлеге Советының эш тәртибе әлеге Устав һәм авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.
2. Авыл җирлеге Советы эшенең төп формасы булып аның утырышлары тора, аларда авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр чишелә.
3. Авыл җирлеге Советы утырышлары, анда сайланган депутатлар санының 50 процентган да ким булмаганы катнашса, хокуклы була.
4. Авыл җирлеге Советының чираттагы утырышлары кирәклеккә күрә, әмма өч айга бер тапкырдан да сирәк түгел үткәрелә. Чираттан тыш утырышлар авыл җирлеге Башлыгы яисә авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән бер өлешеннән дә ким булмаган депутатлар төркеме башлангычы (инициативасы) буенча чакырыла.
5. Совет утырышлары авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан чакырыла. Авыл җирлеге Советы депутатларына һәм чакырылган затларга чираттагы утырышның вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында — ул үткәрелүгә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча, ә чираттан тыш утырыш турында бер көннән дә соңга калмыйча хәбәр ителә.
6. Авыл җирлеге Советы утырышлары ачык һәм ачыклык (гласность) нигезендә үткәрелә. Советның ачык утырышларында авыл җирлегенең теләсә кайсы кешесе катнашырга хокуклы.

   Регламентта күздә тотылган очракларда, авыл җирлеге Советы ябык утырыш үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы, анда авыл җирлеге Советы тарафыннан чакырылган затлар, шулай ук законнар нигезендә утырышта катнашырга хокукы булган затлар гына катнаша ала.

7.Авыл җирлеге Советының һәр утырышында утырыш протоколы алып барыла. Утырыш протоколына утырыш үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты турындагы мәгълүматлар кертелә, карала торган барлык мәсьәләләр санап үтелә һәм тавыш бирү нәтиҗәләре күрсәтелеп, кабул ителгән барлык карарлар теркәлә. Авыл җирлеге Советы утырышы протоколына авыл җирлеге Башлыгы кул куйганнан соң, аның белән авыл җирлегенең теләсә кайсы кешесе таныша ала.

8.Авыл җирлеге Советы утырышларында һәр депутатның бер тавышы бар. Авыл җирлеге Советы депутаты үзенең тавыш бирү хокукын шәхсән үзе гамәлгә ашыра. Авыл җирлеге Советы утырышларында тавыш бирү ачык (шул исәптән исемнәр буенча) һәм ябык (яшерен) булырга мөмкин. Тавыш бирүнең һәр төрен куллану очраклары әлеге Устав, авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнә.

**36 нче статья. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру**

1. Авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыруны авыл җирлеге Башлыгы гамәлгә ашыра.
2. Авыл җирлеге Советы Регламентына ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советы компетенциясенә кертелгән мәсьәләләрне алдан карау һәм әзерләү өчен, авыл

җирлеге Башлыгыннан тыш, депутатлар арасыннан авыл җирлеге Советы эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча даими яисә вакытлы комиссияләр төзелергә һәм (яисә) күрсәтелгән мәсьәләләрне әзерләү өчен җаваплы депутатлар билгеләнергә мөмкин. Депутат икедән артык булмаган даими комиссиядә эшләргә хокуклы.

3. Муниципаль программаларны, авыл җирлеге Советы карарлары проектларын әзерләү, авыл җирлеге карамагына кертелгән аеруча мөһим мәсьәләләрне фикер алышу өчен, авыл җирлеге Советы каршында, аның карары буенча, депутатлар, авыл җирлеге Башкарма комитеты, җәмәгать берләшмәләре, оешмалар һәм предприятиеләр вәкилләре, белгечләр, экспертлар һәм авыл җирлеге халкы составында эшче, эксперт һәм башка киңәшмә төркемнәре төзелергә мөмкин.

## 37 нче статья. Авыл җирлеге Советы тарафыннан контроль функцияләрне гамәлгә ашыру

1. Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге территориясендә әлеге Устав нигезләмәләренең, авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә торган норматив хокукый актларның үтәлешен, авыл җирлеге бюджетының башкарылуын, бюджеттан тыш фондлар акчаларының, авыл җирлеген үстерү программаларының кулланылышын, авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген контрольдә тота.
2. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары тарафыннан законнарны, әлеге Уставны һәм башка муниципаль норматив хокукый актларны бозу фактлары ачыкланган очракта, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы карары буенча, күрсәтелгән фактларны тикшерү өчен депутатлар арасыннан вакытлы контроль комиссияләре төзелергә мөмкин.
3. Законнар нигезендә, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы башлангычы (инициативасы) буенча авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан максатчан файдалануны, муниципаль мөлкәттән файдалануның нәтиҗәлелеген тикшерүләр (ревизияләр) үткәрелергә мөмкин. Күрсәтелгән контроль һәм эксперт-аналитика чараларын үткәрү тәртибе гамәлдәге законнар белән билгеләнә.
4. Авыл җирлеге Башкарма комитеты, предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, вазыйфаи затлар, территория җирле үзидарә органнары, әгәр закон белән башкасы билгеләнмәгән булса, авыл җирлеге Советының, аның контроль комиссияләренең, авыл җирлеге Советы депутатының мөрәҗәгате буенча авыл җирлеге Советы карамагына керүче мәсьәләләр буенча соратыла торган мәгълүматны бирергә, ә законнарны, муниципаль норматив хокукый актларны бозуга күрсәтелгән очракта, хокук бозуларны бетерү һәм гаепле затларны җаваплылыкка тарту өчен кичекмәстән чаралар күрергә бурычлы.
5. Авыл җирлеге Советы авыл җирлеге Башлыгының үз эшчәнлеге нәтиҗәләре, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм җирле үзидарәнең башка ведомство карамагындагы органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән авыл җирлеге

Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне чишү турында еллык хисапларын тыңлый.

6. Авыл җирлеге Советы, контроль функцияләрне гамәлгә ашырганда, авыл җирлеге Башкарма комитетының финанс-хуҗалык һәм башкарма-бөерү эшчәнлегенә кысылырга хокуклы түгел.

**38 нче статья. Муниципаль район Советына авыл җирлеге вәкилен сайлау**

1. Авыл җирлеге вәкиле авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан ТР Лаеш муниципаль районы Советына ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.
2. Авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге үзенең тавышын биргән кандидат сайланган дип санала.

**39 нчы статья. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату**

1. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан элек туктатылырга мөмкин:
1. авыл җирлеге Советы тарафыннан үзен үзе таркату турында карар кабул ителгәндә;
2. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 73 нче статьясында күздә тотылган тәртиптә һәм нигезләр буенча авыл җирлеге Советы таркатылганда;
3. Татарстан Республикасы Югары судының авыл җирлеге Советы депутатларының әлеге составы хокуксыз булуы турындагы (шул исәптән депутатларның үз вәкаләтләрен салуына бәйле рәвештә) карары законлы көченә кергәндә;
4. законнар нигезендә гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеген үзгәртеп корганда, шулай ук авыл җирлеге бетерелгән очракта;
5. авыл җирлеге чикләре үзгәрү яисә җирлекнең шәһәр округы белән берләшүе нәтиҗәсендә авыл җирлеге сайлаучылары саны 25 проценттан күбрәккә артканда;
6. гражданнарның турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны чыгару срогы бозылганда;
7. авыл җирлеге шәһәр округы белән берләшүгә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалткан очракта.
2. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату аның депутатлары вәкаләтләрен вакытыннан элек туктатуга китерә.

3. Авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган очракта, вакытыннан элек сайлаулар федераль закон белән билгеләнгән срокларда үткәрелә.

### 40 нчы статья. Авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату турында карар кабул итү тәртибе

1. Авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату турындагы карар авыл җирлеге Башлыгы яисә авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санынннан яртысыннан кем булмаган күләмдәге депутатлар төркеме башлангычы (инициативасы) буенча кабул ителә ала.
2. Үзен үзе таркату турында карар кабул итү башлангычы түбәндәге очракларда алга сөрелә алмый:
1. авыл җирлеге Советы сайланганнан соң беренче ел дәвамында;
2. авыл җирлеге бюджетын кабул итү һәм аның үтәлеше турындагы хисапны раслау чорында;
3. авыл җирлеге Башлыгын чакырып алу турында тавыш бирү үткәрелгән чорда яисә аның вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган очракта.
3. Авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату турындагы язмача тәкъдимдә үзен үзе таркатуның сәбәпләре (мотивлары) булырга тиеш, шулай ук аңа үзен үзе таркату сәбәпләрен нигезләүче башка материаллар теркәлергә мөмкин.
4. Үзен үзе таркату мәсьәләсен алдан карау өчен, авыл җирлеге Советы карары белән депутатлар арасыннан комиссия төзелә. Авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлеге Башлыгы карары буенча авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату мәсьәләсе ачык тыңлауларга чыгарылырга мөмкин.
5. Авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату мәсьәләсен карау озынлыгы авыл җирлеге Советы депутатлары һәм авыл җирлеге халкы тарафыннан үзен үзе таркату башлангычының барлык бәйлелләрен һәм нигезләмәрен һәрьяклап һәм объектив фикер алышу мөмкинлеген гарантияләргә тиеш. Үзен үзе таркату турындагы карар үзен үзе таркату башлангычы алга сөрәлгән көннәннән башлап ике ай узганнан соң кабул ителә ала.
6. Авыл җирлеге Советын үзен үзе таркату турындагы карар авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән ике өлеше тавышы белән яшерен тавыш бирү юлы белән кабул ителә.
7. Авыл җирлеге Советы тарафыннан үзен үзе таркату турындагы тәкъдим кире кагылган очракта, үзен үзе таркату турындагы кабат башлангыч үзен үзе таркату мәсьәләсе буенча тавыш биргән көннән соң бер ел узганнан да иртәрәк алга сөрелә алмый.

### 41 нче статья. Авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату

1. Авыл җирлеге Советы депутаты вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан элек туктатыла:

1. *вафат булганда;*
2. *үз теләге белән отставкага киткәндә;*
3. *суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләтлелеге чикләнгән дип танылганда;*
4. *суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә үлгән дип игълан ителгәндә;*
5. *аңа карата судның гаепләү хөкем карары законлы көченә кергәндә;*
6. *Россия Федерациясе чикләреннән тыш даими яшәү урынына киткәндә;*
7. *Россия Федерациясе гражданлыгы яисә Россия Федерациясенең халыкара килешүендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгы туктатылганда (әлеге килешү нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия), чит ил дәүләте гражданлыгы (подданлыгы) яисә чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы яшәүгә рөхсәт кәгазе (вид на жительство) яки башка документ булганда — бу Россия Федерациясе гражданына яисә Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы булган чит ил гражданына кагыла, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы күздә тотылмаган булса;*
8. *сайлаучылар тарафыннан чакырылып алынганда;*
9. *авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылганда;*
10. *хәрби хезмәткә чакырылганда яисә аны алыштыручы альтернатив гражданлык хезмәтенә җибәрелгәндә;*
11. *федераль законнарда билгеләнгән башка очракларда.*

2. Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатның вәкаләтләре «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгән очракта вакытыннан элек туктатыла.
3. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләрен туктату турындагы карар әлеге статьяның 1 нче өлешенең 1–8, 10 нчы пунктларында күрсәтелгән очракларда, вәкаләтләрне вакытыннан элек туктату өчен нигез барлыкка килгән көннән башлап 30 көннән дә соңга калмыйча, әгәр бу нигез авыл җирлеге Советы утырышлары арасындагы чорда барлыкка килсә — мондый нигез барлыкка килгән көннән башлап өч айдан да соңга калмыйча авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителә.
4. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре әлеге статьяның 1 нче өлешенең 9 нчы пунктында күздә тотылган очракта, авыл җирлеге Советы вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган көннән башлап туктатыла.
5. Авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган очракта, депутатны өстәмә сайлаулар федераль законга, Татарстан Республикасы Сайлау кодексына ярашлы рәвештә билгеләнә.

6. Татарстан Республикасы Рәисе авыл җирлеге Советы депутатының вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта, вәкаләтләрне вакытыннан элек туктату өчен нигез барлыкка килгән көн булып әлеге гаризаның авыл җирлеге Советына килеп төшкән көне санала.

## IV бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

### 42 нче статья. Авыл җирлеге башлыгы — авыл җирлегенең иң югары вазыйфаи заты

1. Авыл җирлеге башлыгы авыл җирлегенең иң югары вазыйфаи заты булып тора.
2. Авыл җирлеге башлыгы авыл җирлеге Советы тарафыннан сайлана һәм аның рәисе булып тора.
3. Авыл җирлеге башлыгы вазыйфасының рәсми исеме — «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский авыл җирлеге башлыгы».
4. Авыл җирлеге башлыгы үз вазыйфасы буенча Лаеш муниципаль районы Советы депутаты булып тора.
5. Авыл җирлеге башлыгы бер үк вакытта авыл җирлеге Советына һәм авыл җирлеге Башкарма комитетына җитәкчелек итә.

### 43 нче статья. Авыл җирлеге башлыгын сайлау тәртибе

1. Авыл җирлеге башлыгы яңа сайланган авыл җирлеге Советының беренче утырышында авыл җирлеге Советы депутатлары арасыннан, әгәр авыл җирлеге Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, ачык тавыш бирү юлы белән авыл җирлеге Советының вәкаләтләр срогына сайлана.
   Авыл җирлеге Башлыгын сайлау авыл җирлеге Советы депутатлары тарафыннан, шул исәптән авыл җирлеге халкы, җәмәгать берләшмәләре, Татарстан Республикасы Рәисе тәкъдимнәре нигезендә күрсәтелә торган кандидатлар арасыннан гамәлгә ашырыла.
2. Сайлауда авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге үзенең тавышын биргән авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлеге Башлыгы итеп сайланган дип санала.

### 44 нче статья. Авыл җирлеге башлыгы статусы

1. Авыл җирлеге башлыгы даими нигездә эшли.
2. Авыл җирлеге башлыгы ТР Лаеш муниципаль районы Советында даими нигездә биләнә торган вазыйфага сайланган очракта, ул авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыра.

3. Авыл җирлеге башлыгы үз эшчәнлегендә федераль законга һәм әлеге Уставка ярашлы рәвештә авыл җирлеге халкына һәм авыл җирлеге Советына контрольдә тотыла һәм алар алдында хисаплы булып тора.
4. Авыл җирлеге башлыгы елына бер тапкырдан да сирәк түгел авыл җирлеге халкы һәм авыл җирлеге Советы алдында үз эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән авыл җирлеге Советы тарафыннан куелган мәсьәләләрне чишү турында хисап тота.
5. Авыл җирлеге башлыгы «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнары аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон, «Аерым категория затларга Россия Федерациясе территориясеннән тыш урнашкан чит ил банкларында исәп-хисап счетлары (аманатлар) ачарга һәм анда булырга, чит ил банкларында иминиятләштерелгән акча чараларын һәм кыйммәтлелекләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яисә) алардан файдаланырга тыю турында» 2013 елның 7 майдагы 79-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән чикләүләрне, тыюларны сакларга, бурычларны үтәргә тиеш.

**45 нче статья. Авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләре**

Авыл җирлеге башлыгы:

1. башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары, гражданнар һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләрдә авыл җирлеге исеменнән вәкиллек итә, ышаныч кәгазеннән башка авыл җирлеге исеменнән эш итә;
2. авыл җирлеге Советы эшен оештыра, авыл җирлеге Советы утырышларын чакыра һәм аларда рәислек итә, авыл җирлеге Советының чираттан тыш утырышын чакыруны таләп итәргә хокуклы;
3. авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлегенә берлек (бербашлык) принциплары нигезендә җитәкчелек итә һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан үз компетенциясенә керүче вәкаләтләрнең үтәлеше өчен шәхси җаваплылык йөртә;
4. үз вәкаләтләре чикләрендә хокукый актлар чыгара;
5. авыл җирлеге Советы тарафыннан кабул ителгән хокукый актларга кул куя һәм аларны әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгара (халыкка җиткерә);
6. авыл җирлеге Советы эшендә ачыклыкны (гласностьны) һәм җәмәгать фикерен исәпкә алуны тәэмин итү буенча чаралар күрә;
7. авыл җирлеге Советы утырышлары протоколларына кул куя;
8. гражданнарны кабул итүне, аларның мөрәҗәгатьләрен, гаризаларын һәм шикаятьләрен карауны оештыра;
9. расланган бюджетка ярашлы рәвештә үз вәкаләтләре чикләрендә авыл җирлеге акчалары белән эш итә; авыл җирлеге бюджетында авыл җирлеге Советын тоту

һәм аның эшчәнлеген тәэмин итү өчен күздә тотылган чыгымнар буенча акчалар белән эш итүче (распорядитель) булып тора;

10. авыл җирлеге Советы аппараты эшенә җитәкчелек итә;
11. авыл җирлеге Советының контроль вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны координацияли;
12. законга һәм әлеге Уставка ярашлы рәвештә гражданнарның турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру буенча авыл җирлеге Советының хокукый актын кабул итүне оештыра;
13. авыл җирлеге Советы каравына авыл җирлеге бюджеты проектларын һәм аның үтәлеше турындагы хисапларны тәкъдим итә;
14. авыл җирлеге Советы раславына авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасы проектын кертә, расланган структурага, хезмәткәрләрнең билгеләнгән чикке санына һәм хезмәткә түләү фондына ярашлы рәвештә авыл җирлеге Башкарма комитетының штат расписаниесен раслый;

**46 нчы статья. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары**

1. Авыл җирлеге башлыгы тәкъдиме буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан депутатлар арасыннан авыл җирлеге башлыгы урынбасары сайлана.
2. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары, әгәр авыл җирлеге Советы тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, ачык тавыш бирү юлы белән сайлана.
3. Сайлауда авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының яртысыннан күбрәге үзенең тавышын биргән авыл җирлеге Советы депутаты авыл җирлеге Башлыгы урынбасары итеп сайланган дип санала.
4. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнгән бурычларны бүлешүгә ярашлы рәвештә функцияләрне башкара, авыл җирлеге башлыгының йөкләмәләрен үти, ә ул вакытлыча булмаганда (чирле булу яисә отпускка китү сәбәпле) яисә ул үз бурычларын үти алмаганда яисә аның вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган очракта — авыл җирлеге Башлыгы бурычларын гамәлгә ашыра.
5. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыра, әлеге Уставның 40 нчы статьясының 4 нче пунктында күрсәтелгән очрак булып тормаса.
6. Авыл җирлеге башлыгы урынбасары теләсә кайсы вакытта авыл җирлеге Башлыгы башлангычы (инициативасы) буенча яисә авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән бер өлешеннән дә ким булмаган депутатлар төркеме таләбе буенча кабул ителә торган авыл җирлеге Советы карары белән вазыйфасыннан чакырып алынырга мөмкин. Авыл җирлеге башлыгы урынбасарын чакырып алу турындагы карар авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.

**47 нче статья. Авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату**

1. Авыл җирлеге башлыгы вәкаләтләре түбәндәге очракларда вакытыннан элек туктатыла:

1. *вафат булганда;*
2. *үз теләге белән отставкага киткәндә;*
3. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74.1 статьясына ярашлы рәвештә отставкага җибәрелгәндә (чыгарылганда);*
4. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 74 статьясына ярашлы рәвештә вазыйфасыннан читләштерелгәндә;*
5. *суд тарафыннан эшкә сәләтсез яисә эшкә сәләтлелеге чикләнгән дип танылганда;*
6. *суд тарафыннан хәбәрсез югалган дип танылганда яисә үлгән дип игълан ителгәндә;*
7. *аңа карата судның гаепләү хөкем карары законлы көченә кергәндә;*
8. *Россия Федерациясе чикләреннән тыш даими яшәү урынына киткәндә;*
9. *Россия Федерациясе гражданлыгы яисә Россия Федерациясенең халыкара килешүендә катнашучы чит ил дәүләте гражданлыгы туктатылганда (әлеге килешү нигезендә чит ил гражданы җирле үзидарә органнарына сайлану хокукына ия), чит ил дәүләте гражданлыгы (подданлыгы) яисә чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы яшәүгә рөхсәт кәгазе (вид на жительство) яки башка документ булганда — бу Россия Федерациясе гражданына яисә Россия Федерациясенең халыкара килешүе нигезендә җирле үзидарә органнарына сайлану хокукы булган чит ил гражданына кагыла, әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә башкасы күздә тотылган булмаса;*

10. *сайлаучылар тарафыннан чакырылып алынганда;*
11. *сәламәтлек торышы буенча авыл җирлеге Башлыгы вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга сузылган (даими) сәләтсезлеге суд тәртибендә билгеләнгәндә;*
12. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 нче статьясына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеген үзгәртеп корганда, шулай ук авыл җирлеге бетерелгән очракта;*
13. *авыл җирлеге шәһәр округы белән берләшүгә бәйле рәвештә муниципаль берәмлек статусын югалткан очракта;*
14. *муниципаль берәмлек чикләре үзгәрү нәтиҗәсендә авыл җирлеге сайлаучылары саны 25 проценттан күбрәккә артканда;*
15. *гражданнарның турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен таләп ителә торган муниципаль хокукый актны чыгару срогы бозылганда;*

16. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне үтәмәгәндә.*
2. Муниципаль берәмлек башлыгының вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган яисә аңа карата суд карары буенча сак астына алу яки вакытлыча вазыйфасыннан читләштерү рәвешендәге процессуаль мәҗбүр итү чаралары кулланылган очракта, аның вәкаләтләрен вакытлыча җирлек башлыгы урынбасары үти; бу очракта җирлек Башлыгы вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган көннән башлап 6 айдан да соңга калмыйча, җирлек Советы үз составыннан яңа җирлек башлыгын сайлый, әгәр җирлек Советы вәкаләтләре срогы тәмамлануга 6 айдан да кимрәк вакыт калган булса, җирлек башлыгын сайлау яңа сайланган җирлек Советының беренче утырышында гамәлгә ашырыла.
3. Авыл җирлеге башлыгын вазыйфасыннан читләштерү турында Татарстан Республикасы Рәисенең хокукый акты нигезендә яисә авыл җирлеге башлыгын отставкага җибәрү (чыгару) турында авыл җирлеге Советы карары нигезендә вәкаләтләре вакытыннан элек туктатылган авыл җирлеге Башлыгы әлеге хокукый акт яки карар өстеннән суд тәртибендә шикаять биргән очракта, авыл җирлеге Советы, суд карары законлы көченә кергәнчегә кадәр, авыл җирлеге Советы тарафыннан үз составыннан сайлана торган авыл җирлеге башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хокуклы түгел.

## V бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

### 48 нче статья. Авыл җирлеге Башкарма комитеты

1. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлегенең башкарма-бөерү җирле үзидарә органы булып тора.
2. Авыл җирлеге Башкарма комитетының рәсми исеме — Татарстан Республикасы Лаеш муниципального районы Никольский авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль учреждениесе.
3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге Советына хисаплы һәм аның контролендә булып тора.
4. Авыл җирлеге Башкарма комитетының мөхре, авыл җирлеге гербы сурәтләнгән һәм үз исеме язылган бланклары бар.
5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясенә ярашлы рәвештә авыл җирлеге бюджетында аерым юл белән күздә тотыла.

### 49 нчы статья. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасы

1. Башкарма комитет структурасы авыл җирлеге Башлыгы тәкъдиме буенча авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.

2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына түбәндәгеләр керә: Башкарма комитет Җитәкчесе — авыл җирлеге Башлыгы, Башкарма комитет Секретаре, Башкарма комитетның башка вазыйфаи затлары.

**50 нче статья. Авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру**

1. Авыл җирлеге Башкарма комитеты:
1. планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәп-хисап өлкәсендә:
   – авыл җирлеге бюджетын төзи;

   – авыл җирлеге бюджетының башкарылуын тәэмин итә, авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен үтәүне оештыра;

   – авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисап, авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш стратегиясен үтәү турында хисаплар әзерли;

   – авыл җирлегенең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын сыйфатлаучы статистика күрсәткечләрен җыюны һәм күрсәтелгән мәгълүматларны Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарына тәкъдим итүне оештыра;

   – авыл җирлегенең транспорт инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын һәм авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программаларын гамәлгә ашыра, аларның таләпләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә;

2. муниципаль мөлкәт белән идарә итү, авыл җирлеге территориясендәге предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара мөнәсәбәтләр өлкәсендә:
   – авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт белән идарә итә, муниципаль мөлкәт объектларын төзү, сатып алу, файдалану, аңа эш итү һәм аны арендага бирү мәсьәләләрен чишә;

   – авыл җирлеге Советы карары белән билгеләнә торган очракларда, муниципаль мөлкәтне читкә юнәлтү, шул исәптән аны хосусыйлаштыру турындагы тәкъдимнәрне әзерли һәм авыл җирлеге Советына килештерү (раслау) өчен кертә;

   – муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, оешмалар белән авыл җирлегенең икътисади һәм социаль үсешендә хезмәттәшлек турында шартнамәләр төзи; авыл җирлеге территориясендә халыкка хезмәт күрсәтү өлкәсендә төрле милек формасындагы предприятиеләр төзүгә ярдәм итә;

   – авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, аларның эшчәнлек максатларын, шартларын һәм тәртибен билгеләп үтә, уставларын раслый, муниципаль казна учреждениеләрен финанслауны тәэмин итә, муниципаль

учреждениеләрне һәм предприятиеләрне үзгәртеп кору һәм бетерү мәсьәләләрен чишә, контракт нигезендә аларның җитәкчеләрен вазыйфага билгели һәм биләгән вазыйфаларыннан азат итә;

– муниципаль заказны формалаштыра һәм урнаштыра; бюджет һәм автоном муниципаль учреждениеләр тарафыннан муниципаль йөкләмәнең үтәлешен финанс ягыннан тәэмин итә; авыл җирлеген төзекләндерү, халыкка коммуналь хезмәтләр күрсәтү, социаль инфраструктура объектларын төзү һәм ремонтлау, халыкның көнкүреш һәм социаль-мәдәни ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен кирәкле продукция җитештерү, хезмәтләр күрсәтү буенча эшләрне башкаруга, моның өчен күздә тотылган авыл җирлегенең үз матди һәм финанс акчаларын файдаланып башка эшләрне үтәүгә заказчы булып чыга;

– әгәр федераль законнарда башкасы күздә тотылмаган булса, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә һәм муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр тарафыннан башкарыла торган эшләрне башкаруга тарифлар билгели;

– кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;

3. территорияне планлаштыру, җирдән һәм башка табигый ресурслардан файдалану, әйләнә-тирә табигый мохитне саклау өлкәсендә:
– муниципаль милектә булган җирләрдән рациональ файдалануны һәм аларны саклауны планлаштыруны яисә оештыруны гамәлгә ашыра;

– законнарда билгеләнгән тәртиптә авыл җирлеге территориясендәге җир участокларын бирә һәм тартып ала, шул исәптән сатып алу юлы белән;

– халыкка экологик вазгыять турында мәгълүмат бирә, тиешле органнарга предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның әйләнә-тирә мохиткә куркыныч тудыручы, табигатьтән файдалану турындагы законнарны бозучы гамәлләре турында хәбәр итә;

4. транспорт һәм элемтә өлкәсендә:
– авыл җирлеге территориясендә эшләүче җәмәгать транспортының маршрутларын, хәрәкәт графикларын, тукталыш урыннарын раслый яисә килештерә;

– җәмәгать транспорты тукталышлары өчен бүлеп бирелгән урыннарны төзекләндерүне тәэмин итә;

– халыкны элемтә хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыруны тәэмин итә;

5. авыл хуҗалыгын һәм эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә:
– авыл хуҗалыгы җитештерүен үстерү һәм авыл хуҗалыгы продукциясе, чимал һәм азык-төлек базарларын киңәйтү өчен шартлар, кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өчен шартлар тудыра;
6. халыкка көнкүреш, сәүдә һәм башка төрле хезмәт күрсәтү өлкәсендә:

– халыкны җәмәгать туклануы, сәүдә һәм көнкүреш хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра; базарлар һәм ярминкәләр оештыра;

– авыл җирлеге территориясендә физик культураны, мәктәп спортын һәм массакүләм спортны үстерү, авыл җирлегенең рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тәэмин итә;

– балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чараларны оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшләп чыгара һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен тормышка ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшләп чыгара һәм гамәлгә ашыра, җирлектә яшьләр сәясәтен тормышка ашыру мониторингын оештыра һәм гамәлгә ашыра;

– ритуал (җеназа) хезмәтләре күрсәтүне оештыра һәм җирләү урыннарын (зыяратларны) тотуны тәэмин итә.

7. торак-коммуналь хуҗалык һәм төзекләндерү өлкәсендә:
– каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм ташу буенча эшчәнлекне оештыруда катнаша;

– төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контроль гамәлгә ашыра, аның предметы булып җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен, инвалидлар өчен социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларының һәм күрсәтелә торган хезмәтләрнең үтемлелеген тәэмин итү таләпләрен саклау, күрсәтелгән кагыйдәләргә ярашлы рәвештә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру тора;

– адреслау объектларына адреслар бирә, адресларны үзгәртүне, гамәлдән чыгаруны, урам-юл челтәре элементларына (федераль әһәмияттәге автомобиль юлларын, региональ яисә муниципальара әһәмияттәге, муниципаль районның җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын исәпкә алмыйча) исемнәр бирүне, авыл җирлеге чикләрендә планлаштыру структурасы элементларына исемнәр бирүне, мондый исемнәрне үзгәртүне, гамәлдән чыгаруны, дәүләт адрес реестрында мәгълүмат урнаштыруны гамәлгә ашыра;

– Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә авыл җирлеге чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне, суны агызуны (водоотведение), халыкны ягулык белән тәэмин итүне оештыра;

– авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеген оештыра;

– авыл җирлеге халкының массакүләм ялы өчен шартлар тудыра һәм халыкның массакүләм ял итү урыннарын оештыруны, шул исәптән гражданнарның гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итүне оештыра;

8. гражданнарның хокукларын һәм иреген саклау, законлылыкны тәэмин итү, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә.

9. – авыл җирлеге территориясендә законнарның, дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнары актларының үтәлешен, гражданнарның хокукларын һәм ирегеn саклауны тәэмин итә;

10. – җирле үзидарә хокукларын бозучы дәүләт хакимияте органнары һәм дәүләт вазыйфаи затларының, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең, оешмаларның актлары өстеннән билгеләнгән тәртиптә, шул исәптән судта яисә арбитраж судта шикаять бирә;

11. – авыл җирлеге торак пунктлары чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын үткәрүне тәэмин итә;

12. – муниципаль сайлауларны, җирле референдумны, авыл җирлеге депутатын чакырып алу буенча тавыш бирүне, авыл җирлеге чикләрен үзгәртү, авыл җирлеген үзгәртеп кору мәсьәләләре буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм үткәрүне оештыру һәм матди-техник ягыннан тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

13. – җыелышлар, митинглар, урам барышлары, демонстрацияләр һәм пикетлаулар үткәрүгә, спорт, тамаша һәм башка массакүләм җәмәгать чараларын оештыруга бәйле булган, законнарда күздә тотылган чараларны гамәлгә ашыра;

14. – җәмәгать тәртибен саклауда катнашучы гражданнарга һәм аларның берләшмәләренә ярдәм күрсәтә, халык дружиналары эшчәнлеге өчен шартлар тудыра;

15. – милләтара һәм конфессияара татулыкны ныгытуга, авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе халыкларының телләрен һәм мәдәниятен саклауга һәм үстерүгә, мигрантларны социаль һәм мәдәни җайлаштыруга (адаптацияләүгә), милләтара (этнослара) низагларны профилактикалауга юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

16. – гаилә законнарында билгеләнгән тәртиптә уналты яше тулган затларга никахка керүгә рөхсәт бирә;

9. мәдәният өлкәсендә:

– халыкның буш вакытын оештыру һәм аны мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү өчен шартлар тудыра;

– авыл җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль музейларны тотуны тәэмин итә;

10. федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен үтәү өлкәсендә:

– федераль законнарга һәм Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра;

– дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән матди һәм финанс акчаларының исәбен алып бара һәм алардан тиешенчә файдалануны тәэмин итә;

– бирелгән дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру турындагы хисапларны тиешле федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә тәкъдим итә;

11. башка вәкаләтләр:
– авыл җирлеге Башлыгы эшчәнлеген оештыру, хокукый, мәгълүмати, матди-техник һәм башка төрле тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

– авыл җирлегенең архив фондларын формалаштыруны тәэмин итә;

– авыл җирлеге территориясендә үткәрелә торган социаль әһәмияттәге һәм башка чараларны (Картлар һәм инвалидлар декадасы, Җиңү көне һ.б.) оештыруны гамәлгә ашыра;

– законнар, әлеге Устав, авыл җирлеге Советы карарлары белән авыл җирлеге Советы яисә авыл җирлегенең башка җирле үзидарә органнары компетенциясенә кертелгән вәкаләтләрне исәпкә алмыйча, авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләре буенча башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

2. Башкарма комитет авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләренә кертелмәгән мәсьәләләрне чишү буенча түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:
– авыл җирлеге музейларын төзи;

– авыл җирлегендә нотариус булмаган очракта, законнарда күздә тотылган нотариаль гамәлләрне кыла;

– опека һәм попечительлек буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнаша;

– авыл җирлеге территориясендә җирле милли-мәдәни автономияләрнең хокукларын тормышка ашыруга бәйле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен шартлар тудыра;

– авыл җирлеге территориясендә Россия Федерациясе халыкларының милли-мәдәни үсешенә һәм милләтара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга ярдәм күрсәтә;

– авыл җирлеге территориясендә урнашкан муниципаль предприятиеләрне һәм учреждениеләрне мобилизацион әзерләү буенча чараларны оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнаша;

– муниципаль янгыннан саклау хезмәтен төзи;

– туризмны үстерү өчен шартлар тудыра;

– кеше хокукларын тәэмин итүне җәмәгатьчелек тарафыннан контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы җәмәгать күзәтүе комиссияләренә ярдәм күрсәтә һәм мәҗбүри тоту урыннарында булган затларга булышлык итә;

– «Инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, инвалидларның җәмәгать берләшмәләренә, шулай ук бөтенроссия инвалидлар җәмәгать берләшмәләре тарафыннан төзелгән оешмаларга ярдәм күрсәтә;

– торак законнарына ярашлы рәвештә, гражданнарга социаль билгеләнештәге торак фондының торак бүлмәләрен яллау шартнамәләре буенча муниципаль торак фондыннан торак бүлмәләр бирә;

– хуҗасыз этләр һәм мәчеләр (иясе булмаган хайваннар) белән эш итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда чаралар оештыра;

– «Россия Федерациясендә хокук бозуларны профилактикалау системасы нигезләре турында» Федераль законнарында күздә тотылган хокук бозуларны профилактикалау өлкәсендә чараларны гамәлгә ашыра;

– инвалидларның, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән затларның физик культурасын һәм спортын, адаптив физик культураны һәм адаптив спортны үстерүгә ярдәм күрсәтә;

– «Кулланучыларның хокукларын яклау турында» Россия Федерациясенең 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Законында күздә тотылган кулланучылар хокукларын яклау буенча чараларны гамәлгә ашыра;

полициянең участок вәкаләтлесе вазыйфасын биләүче хезмәткәргә һәм аның гаиләә әгъзаларына, хезмәткәр күрсәтелгән вазыйфаны биләгән чорга, торак бүлмәсе бирә;

– алкоголь, наркотик яисә башка токсик исерткечләр йогынтысында булган затларга ярдәм күрсәтү буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3. Авыл җирлеге Башкарма комитеты муниципаль контроль гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган булып тора.
   Муниципаль контроль өлкәсендә авыл җирлеге Башкарма комитеты вәкаләтләренә түбәндәгеләр керә:

1. муниципаль контроль гамәлгә ашырылганда дәүләт контроле (күзәтчелеге), муниципаль контроль өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен тормышка ашыруда катнашу;
2. муниципаль берәмлек территориясендә муниципаль контрольне оештыру һәм гамәлгә ашыру;
3. федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында күздә тотылган башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыру.
   Муниципаль контрольне турыдан-туры гамәлгә ашыру буенча функцияләр, мондый органнарның статусын билгеләүче хокукый актларга ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Башкарма комитеты органнарына йөкләнергә мөмкин.

Муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга, юридик затларны, индивидуаль эшкуарларны тикшерүне оештыруга һәм үткәрүгә бәйле мөнәсәбәтләргә «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләре кулланыла.

## VI бүлек. ҖИРЛӘ ЕҮЗИДАРӘНЕҢ БАШКА ОРГАННАРЫ. ҖИРЛӘ ЕҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕГЕ

### 51 нче статья. Авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Башкарма комитеты һәм авыл җирлегенең башка җирле үзидарә органнары үзара хезмәттәшлегенең нигезләре

1. Әлеге Устав белән билгеләнгән вәкаләтләрне бүлешүгә ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советы, авыл җирлеге Башлыгы һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты үз вәкаләтләрен мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашыралар.
2. Авыл җирлеге Советы һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты, авыл җирлегенең икътисади һәм социаль үсеш процесслары белән нәтиҗәле идарә итү максатыннан һәм аның халкы мәнфәгатьләрендә, законнарда, әлеге Уставта билгеләнгән формаларда үзара хезмәттәшлек итәргә бурычлы.
3. Авыл җирлеге Советы һәм авыл җирлеге Башкарма комитеты кабул ителгән норматив хокукый актларны, аларны имзалаган көннән башлап җиде көнлек срокта, бер-берсенә җибәрәләр.
4. Авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе буларак, авыл җирлеге Советына авыл җирлеге Советының, авыл җирлеге Башлыгының хокукый актларын кабул итү, гамәлдән чыгару, үзгәртү турында тәкъдим белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы, шулай ук алар өстеннән суд тәртибендә шикаять бирергә хокукы бар.
5. Авыл җирлегенең башка җирле үзидарә органнарының үзара хезмәттәшлек тәртибе авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнергә мөмкин.

### 52 нче статья. Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасындагы бәхәсләрне чишү

Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары арасында үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру мәсьәләләре буенча бәхәсләр килештерү процедуралары үткәрү юлы белән яисә суд тәртибендә чишелә.

## VIII бүлек. ҖИРЛӘ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫ ЭШЧӘНЛЕГЕНЕҢ ГРАЖДАНЛЫК-ХОКУКЫЙ ҺӘМ ФИНАНС НИГЕЗЛӘРЕ

### 53 нче статья. Юридик зат хокукларына ия булган авыл җирлеге җирле үзидарә органнары

1. Федераль законга һәм әлеге Уставка ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советына һәм авыл җирлеге Башкарма комитетына юридик зат хокуклары бирелә.
2. Авыл җирлеге Башкарма комитеты структурасына ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советы карары буенча авыл җирлеге Башкарма комитетының аерым органнарына юридик зат хокуклары бирелә ала.

### 54 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары юридик затлар буларак

1. Авыл җирлеге исеменнән мөлкәти һәм башка хокукларны һәм бурычларны сатып алырга һәм гамәлгә ашырырга, ышаныч кәгазеннән башка судта чыгыш ясарга авыл җирлеге Башлыгы хокуклы.
2. Юридик зат хокуклары бирелгән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары идарә итү функцияләрен гамәлгә ашыру өчен төзелә торган муниципаль казна учреждениеләре булып торалар һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә юридик затлар буларак дәүләт теркәве узарга тиешләр.

### 55 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарын финанслау

1. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген финанс ягыннан тәэмин итү бары тик авыл җирлеге бюджетының үз керемнәре исәбенә генә гамәлгә ашырыла.
2. Законнарда, әлеге Уставта, авыл җирлеге Советы карарларында күздә тотылган очракларда, авыл җирлеге җирле үзидарә органнары эшчәнлеген тәэмин итүгә чыгымнар Россия Федерациясе бюджетлары чыгымнары классификациясенә ярашлы рәвештә авыл җирлеге бюджетында аерым юл белән күздә тотыла.

## IX бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫНА ҺӘМ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ БАШКА ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНА БЕРЕЛӘ ТОРГАН СОЦИАЛЬ ҺӘМ БАШКА ГАРАНТИЯЛӘР

### 56 нче статья. Авыл җирлеге башлыгына һәм авыл җирлегенең башка вазыйфаи затларына бирелә торган социаль һәм башка гарантияләр

Авыл җирлеге башлыгы һәм авыл җирлегенең башка вазыйфаи затлары эшчәнлегенең социаль һәм башка гарантияләре «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатының, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затының вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре

турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына һәм авыл җирлеге Советы карарларына ярашлы рәвештә билгеләнә.

### 57 нче статья. Авыл җирлеге Советы депутатының, башка вазыйфаи затларның эшчәнлек ителүенә социаль һәм башка гарантияләр

1. Авыл җирлеге Советының даими булмаган нигездә эшләүче депутатына авыл җирлеге Советы һәм аның органнары утырышларында катнашкан, авыл җирлеге Советының йөкләмәләрен үтәгән вакыт өчен гамәлдәге законнарда күздә тотылган акчалата компенсация һәм башка түләүләр түләнә.
   Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатына үз вәкаләтләрен даими булмаган нигездә гамәлгә ашыру өчен эш урыны (вазыйфасы) саклану гарантияләнә, аның дәвамлылыгы Россия Федерациясе субъекты законы нигезендә муниципаль берәмлек уставы белән билгеләнә һәм аена җыелма рәвештә ике эш көненнән дә кимрәк һәм алты эш көненнән дә күбрәк булырга мөмкин түгел.

### 58 нче статья. Авыл җирлеге Башлыгының, авыл җирлеге Советы депутатларының кагылсызлык гарантияләре

1. Авыл җирлеге Советы депутатларының, шул исәптән авыл җирлеге Башлыгының хокуклары гарантияләре аларны җинаять яисә административ җаваплылыкка тартканда, тоткарлаганда, кулга алганда, тентегәндә, сорау алганда, аларга карата башка җинаять-процессуаль һәм административ-процессуаль гамәлләр кылганда, шулай ук депутатларга, алар биләгән торак һәм (яисә) хезмәт биналарына, аларның багажына, шәхси һәм хезмәт транспорт чараларына, язышуларына, алар файдалана торган элемтә чараларына, аларга караган документларга карата оператив-эзләнү чаралары үткәргәндә федераль законнар белән билгеләнә.
2. Федераль законга ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Советы депутаты әйткән фикере, тавыш биргәндә белдергән позициясе һәм үз статусына туры килә торган башка гамәлләре өчен, шул исәптән үз вәкаләтләре срогы тәмамланганнан соң да, җинаять яисә административ җаваплылыкка тартыла алмый. Әлеге нигезләмә авыл җирлеге Советы депутаты тарафыннан халык алдында мыскыллаулар, яла ягулар яисә федераль закон нигезендә җаваплылык күздә тотылган башка хокук бозулар очракларына кагылмый.

## X бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ ҖИРЛӘ ЕҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫНЫҢ ҺӘМ ВАЗЫЙФАИ ЗАТЛАРЫНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

### 59 нчы статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының җаваплылыгы

Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары авыл җирлеге халкы, дәүләт, физик һәм юридик затлар алдында законнар нигезендә җаваплылык йөртәләр.

**60 нчы статья. Авыл җирлеге Советы депутатларының авыл җирлеге халкы алдындагы җаваплылыгы**

1. Авыл җирлеге Советы депутатларының, шул исәптән авыл җирлеге башлыгының авыл җирлеге халкы алдындагы җаваплылыгы тиешле депутатның үзен сайлаган авыл җирлеге халкы ышанычын югалтуы нәтиҗәсендә барлыкка килә.
2. Авыл җирлеге халкы ышанычын югалткан авыл җирлеге Советы депутаты, шул исәптән авыл җирлеге башлыгы, әлеге Уставта күздә тотылган нигезләр буенча һәм тәртиптә чакырып алынырга мөмкин.

**61 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының дәүләт алдындагы җаваплылыгы**

1. Федераль законнар нигезендә, авыл җирлеге Советының, авыл җирлеге башлыгының дәүләт алдындагы җаваплылыгы алар тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, федераль конституцион законнар, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Устав бозылган очракта, шулай ук авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен тиешенчә гамәлгә ашырмаган очракта, тиешле суд карары нигезендә барлыкка килә.
2. Авыл җирлеге Советын таркату, авыл җирлеге башлыгын, авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесен вазыйфасыннан читләштерү һәм отставкага җибәрү (чыгару) нигезләре һәм тәртибе «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнелә.

**62 нче статья. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларны ышанычны югалту сәбәпле эштән бушату (вазыйфасыннан азат итү)**

1. Муниципаль вазыйфаны б
2. иләүче зат федераль законнарда, Татарстан Республикасы законнарында, муниципаль норматив хокукый актларда күздә тотылган тәртиптә, түбәндәге очракларда ышанычны югалту сәбәпле эштән бушатылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш:

1. *федераль законнарда билгеләнгән очракларны исәпкә алмыйча, әлеге зат үзе ягы булган мәнфәгатьләр низагын кисәтү һәм (яисә) җайга салу буенча чаралар күрмәгәндә;*

2. *федераль законнарда билгеләнгән очракларны исәпкә алмыйча, әлеге зат үзенең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти сыйфаттагы йөкләмәләре турында, шулай ук үзенең хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти сыйфаттагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тәкъдим итмәгәндә, тулы булмавы алдан билгеле булган мәгълүматлар тәкъдим иткәндә, яисә дөрес түгеллеге алдан билгеле булган мәгълүматлар тәкъдим иткәндә;*
3. *федераль законда билгеләнгән очракларны исәпкә алмыйча, әлеге зат коммерция оешмасының идарә органы эшчәнлегендә түләүле нигездә катнашканда;*
4. *әлеге зат эшкуарлык эшчәнлеге алып барганда;*
5. *әгәр Россия Федерациясенең халыкара килешүендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы күздә тотылмаган булса, әлеге зат чит ил коммерциягә карамаган хөкүмәткә карамаган оешмаларының һәм аларның Россия Федерациясе территориясендә эшләүче структур бүлекчәләренең идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, башка органнары составына кергәндә.*

2.Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, узенә буйсынган затта мәнфәгатьләр низагына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килүе турында билгеле булган очракта, шулай ук — узенә буйсынган зат ягы булган мәнфәгатьләр низагын кисәтү һәм (яисә) җайга салу буенча чаралар күрмәгәндә (федераль законнарда билгеләнгән очракларны исәпкә алмыйча), ышанычны югалту сәбәпле эштән бушатылырга (вазыйфасыннан азат ителергә) тиеш.

### 63 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы

Авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының һәм җирле үзидарә вазыйфаи затларының физик һәм юридик затлар алдындагы җаваплылыгы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә барлыкка килә.

## XI бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ МУНИЦИПАЛЬ ХОКУКЫЙ АКТЛАРЫ

### 64 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасы

1. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары системасына түбәндәгеләр керә:
1. *авыл җирлеге Уставы, җирле референдумда (гражданнар җыенында) кабул ителгән хокукый актлар;*
2. *авыл җирлеге Советының норматив һәм башка хокукый актлары;*
3. *әлеге Уставта күздә тотылган авыл җирлеге Башлыгының, Башкарма комитетның һәм җирле үзидарәнең башка органнарының һәм вазыйфаи затларының норматив һәм башка хокукый актлары.*

2. Авыл җирлеге Уставы һәм хокукый актлар рәвешендә рәсмиләштерелгән җирле референдумда кабул ителгән карарлар муниципаль хокукый актлар системасында иң югары юридик көчкә ия булган актлар булып торалар, турыдан-туры көчкә ия һәм авыл җирлегенең бөтен территориясендә кулланылалар.
Башка муниципаль хокукый актлар әлеге Уставка һәм җирле референдумда кабул ителгән хокукый актларга каршы килергә тиеш түгел.

3. Җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителгән муниципаль хокукый актлар авыл җирлегенең бөтен территориясендә мәҗбүри үтәлергә тиеш.
4. Муниципаль хокукый актлар тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлдән чыгарылырга яисә аларның кануны (эше) вакытлыча туктатылырга мөмкин; мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар бетерелгән яки күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта — муниципаль хокукый актны гамәлдән чыгару яки аның кануны вакытлыча туктату моментына тиешле муниципаль хокукый актны кабул итү (чыгару) вәкаләтләренә кертелгән җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан, шулай ук суд тарафыннан гамәлдән чыгарылырга яисә вакытлыча туктатылырга мөмкин; ә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны көйли торган өлешендә — Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт хакимияте органы тарафыннан да гамәлдән чыгарылырга яисә вакытлыча туктатылырга мөмкин.

5. Норматив характерда булмаган муниципаль хокукый актның кануны (эше) — Россия Федерациясенең эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтлеләре турындагы законнарына ярашлы рәвештә бирелгән, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле затның тиешле күрсәтмәсе (предписаниесе) алынган очракта, аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә вазыйфаи заты тарафыннан кичекмәстән вакытлыча туктатыла. Авыл җирлеге Башкарма комитеты яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле затка өч көнлек срокта, ә авыл җирлеге Советы үзләре карар кабул иткән көннән башлап өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.

**65 нче статья. Авыл җирлеге гражданнарының турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарлар**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне турыдан-туры авыл җирлеге халкы тарафыннан чишү җирле референдумда белдерелгән гражданнарның турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән гамәлгә ашырыла.
2. Әгәр авыл җирлеге халкының турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен өстәмә рәвештә муниципаль норматив хокукый актны кабул итү (чыгару) таләп ителсә, компетенциясенә күрсәтелгән актны кабул итү (чыгару) керүче авыл җирлеге җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә вазыйфаи заты референдумда кабул ителгән карар законлы көченә кергән көннән башлап 15 көн дәвамында тиешле муниципаль норматив хокукый актны әзерләү һәм (яисә) кабул итү срогын билгеләргә бурычлы. Күрсәтелгән срок өч айдан артып китә алмый.
3. Гражданнарның турыдан-туры ихтыяри белдерүе юлы белән кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль норматив хокукый актны чыгару срогын бозу авыл җирлеге Башлыгын чакырып алу яисә авыл җирлеге Советы вәкаләтләрен вакытыннан элек туктату өчен нигез булып тора.

**66 нчы статья. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренең эчтәлеге**

1. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре авыл җирлеге Советы тарафыннан раслана.
2. Авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләре түбәндәге мәсьәләләрне көйли ала:

1. *гомуми файдаланудагы территорияләрне тоту һәм мондый территорияләрдән файдалану тәртибе;*
2. *биналарның, рәвешләрнең, корылмаларның фасадларының һәм коймалау конструкцияләренең тышкы күренеше;*
3. *төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, тоту һәм торгызу, шул исәптән җир эшләре үткәргәннән соң;*
4. *авыл җирлеге территориясен яктыртуны оештыру, шул исәптән биналарның, рәвешләрнең, корылмаларның архитектура яктыртылышын (подсветкасын);*
5. *авыл җирлеге территориясен яшелләндерүне оештыру, шул исәптән торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннарны, чәчәклекләрүне һәм үлән үсемлекләре биләгән башка территорияләрне төзү, тоту, торгызу һәм саклау тәртибе;*
6. *авыл җирлеге территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары язылган күрсәткечләрне, элмәләрне урнаштыру;*
7. *балалар һәм спорт мәйданчыкларын, хайваннарны йөртү мәйданчыкларын, парковкаларны (парковка урыннарын), кече архитектура формаларын урнаштыру һәм тоту;*
8. *җәяүлеләр коммуникацияләрен, шул исәптән тротуарларны, аллеяларны, юлларны, сукмакларны оештыру;*

9. *инвалидларның һәм халыкның башка аз мобильле төркемнәренең күрсәтелгән территория буенча тоткарлыксыз хәрәкәт итүен тәэмин итү максатыннан авыл җирлеге территориясен җайлаштыру;*
10. *авыл җирлеге территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда;*
11. *яңгыр суларын агызуны оештыру;*
12. *җир эшләрен үткәрү тәртибе;*
13. *биналарның, рәвешләрнең, корылмаларның, җир участокларының милекчеләре һәм (яисә) башка законлы хуҗаларының (күпфатирлы йортлардагы торак бүлмәләрнең милекчеләрен һәм (яисә) башка законлы хуҗаларын исәпкә алмыйча, әгәр алар астындагы җир участоклары формалаштырылмаган булса яисә мондый йортларның чикләре буенча формалаштырылган булса) чиктәш территорияләрне тотуда катнашуы, шул исәптән финанс ягыннан;*
14. *Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртипкә ярашлы рәвештә чиктәш территорияләрнең чикләрен билгеләү;*
15. *авыл җирлеге территориясен бәйрәмчә бизәү;*
16. *авыл җирлеге территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда гражданнарның һәм оешмаларның катнашу тәртибе.*

**67 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары тарафыннан кабул ителә торган муниципаль хокукый актларның төрләре**

1. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлары үзләренә йөкләнгән вәкаләтләрне үтәү йөзеннән түбәндәге муниципаль хокукый актларны чыгаралар:
1. авыл җирлеге Советы — авыл җирлеге Советы карарларын;
2. авыл җирлеге Башлыгы — авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча карарлар һәм күрсәтмәләр (распоряжениеләр), җирлек Башкарма комитеты карарларын һәм күрсәтмәләрен;
2. Җирле үзидарәнең башка вазыйфаи затлары әлеге Устав, аларның статусын билгеләүче башка муниципаль норматив хокукый актлар белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә күрсәтмәләр (распоряжениеләр) һәм боерыклар чыгаралар.

**68 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын әзерләү**

1. Муниципаль хокукый актлар проектлары авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, Прокурор, территория җирле үзидарә органнары, гражданнарның инициативалы төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.
2. Прокурор, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыру барышында гамәлдәге муниципаль норматив хокукый актларны камилләштерү кирәклеген билгеләгәндә, муниципаль норматив хокукый актларны үзгәртү, гамәлдән чыгару яисә кабул итү турында тәкъдимнәр кертергә хокуклы.

3. Муниципаль хокукый актлар проектларын кертү тәртибе, аларга теркәлә торган документларның исемлеге һәм формасы тиешлечә авыл җирлеге Советы Регламенты һәм авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан билгеләнә.

### 69 нчы статья. Авыл җирлеге Советының хокукый актлары

1. Авыл җирлеге Советы, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Устав белән үз компетенциясенә кертелгән мәсьәләләр буенча, авыл җирлеге территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган карарлар, авыл җирлеге Башлыгын отставкага җибәрү (чыгару) турында карар, шулай ук авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав белән үз компетенциясенә кертелгән башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итә.
2. Авыл җирлеге территориясендә үтәү өчен мәҗбүри булган кагыйдәләрне билгели торган авыл җирлеге Советы карарлары, әгәр федераль законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының күпчелек тавышы белән кабул ителә.
3. Җирле салымнарны һәм җыемнарны билгеләүне, үзгәртүне һәм гамәлдән чыгаруны, авыл җирлеге бюджеты акчаларыннан чыгымнар гамәлгә ашыруны күздә тоткан авыл җирлеге Советы карарлары авыл җирлеге Советы каравына авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе башлангычы (инициативасы) буенча яисә аның бәяләмәсе (заключениесе) булганда гына кертелә ала. Күрсәтелгән бәяләмә аның тарафыннан авыл җирлеге Советына авыл җирлеге Советы Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә утыз көнлек срокта тәкъдим ителә.
4. Авыл җирлеге Советы карарларына авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан алар кабул ителгән көннән башлап өч көнлек срокта кул куела һәм алар аның тарафыннан әлеге Уставта билгеләнгән тәртиптә рәсми бастырып чыгарыла (халыкка җиткәрелә).

### 70 нче статья. Авыл җирлеге башлыгының хокукый актлары

Авыл җирлеге башлыгы, законнар, әлеге Устав, авыл җирлеге Советы карарлары белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә, авыл җирлеге Советы эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга һәм башка федераль законнарга ярашлы рәвештә авыл җирлеге Уставы белән аның вәкаләтләренә кертелгән башка мәсьәләләр буенча хокукый актлар чыгара.

Авыл җирлеге башлыгы, федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, әлеге Устав, авыл җирлеге Советының норматив хокукый актлары белән билгеләнгән үз вәкаләтләре чикләрендә, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр һәм федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары белән җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләр буенча Башкарма комитет карарларын, шулай ук авыл җирлеге

Башкарма комитеты эшен оештыру мәсьәләләре буенча авыл җирлеге Башкарма комитеты күрсәтмәләрен (распоряжениеләрен) чыгара.

**71 нче статья. Муниципаль норматив хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм аларның законлы көченә керү тәртибе**

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирегенә һәм бурычларына кагыла торган муниципаль норматив хокукый актлар, муниципаль берәмлек оештыручысы булып чыгыш ясаучы оешмаларның хокукый статусын билгели торган муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр аларны рәсми рәвештә халыкка җиткергәннән (обнародование ясаганнан) соң законлы көченә керәләр.
2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең тулы текстын рәсми рәвештә халыкка җиткерү булып аларны түбәндәгечә башкару санала:

*1. Текстын тулысынча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru (ММЧ теркәү турындагы таныклык ЭЛ № ФС 77-60244, 17.12.2014 елны Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан бирелгән) яисә Лаеш муниципаль районының «Камская новь» («Кама ягы») газетасында (ТР буенча Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт идарәсе, теркәү номеры ПИ №ТУ16-01035, 16.05.2013 елдан) рәсми бастырып чыгару.*

*2. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Никольский авыл җирлегенең рәсми сайтында http://laishevo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру.*

*3. Түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру: Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге поселок, Үзәк урам, 7А нчы йорт.*

*3. Гражданнарның Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталына керүен тәэмин итү өчен, түбәндәге адрес буенча урнашкан Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәренә тоташу пунктлары эшли: Лаеш районы, 25 Октябрь исемендәге поселок, Үзәк урам, 7А нчы йорт.*

*4. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, аларга кул куелган көннән башлап 10 көн дәвамында халыкка җиткерелә (обнародование ясала), таратылуы федераль закон белән чикләнгән мәгълүматларны үз эченә алган муниципаль хокукый актлар яисә аларның аерым нигезләмәләре моннан чыгарма булып тора.*

*5. Никольский авыл җирлегенең салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясенең Салым кодексына ярашлы рәвештә законлы көченә керәләр.*

6. *Әлеге статьяның 1 нче пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр актның үзендә башкасы билгеләнмәгән булса, аларга кул куелган көннән башлап законлы көченә керәләр.*
7. *Периодик басма массакүләм мәгълүмат чараларының, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге тиешле сайтларның домен исемнәре һәм аларны массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәү турындагы мәгълүматлар күрсәтелгән челтәр басмаларының исемлеге (аларда муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне халыкка җиткерү гамәлгә ашырыла, рәсми бастырып чыгару моннан чыгарма булып тора) муниципаль берәмлек Башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.*

### 72 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актларын гамәлдән чыгару һәм аларның канунын (эшен) вакытлыча туктату

1. Авыл җирлегенең муниципаль хокукый актлары тиешле муниципаль хокукый актны кабул иткән (чыгарган) авыл җирлеге җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлдән чыгарылырга яисә аларның кануны вакытлыча туктатылырга мөмкин; мондый органнар яисә тиешле вазыйфалар бетерелгән яки күрсәтелгән органнарның яисә вазыйфаи затларның вәкаләтләре исемлеге үзгәргән очракта — муниципаль хокукый актны гамәлдән чыгару яки аның канунын вакытлыча туктату моментына тиешле муниципаль хокукый актны кабул итү (чыгару) вәкаләтләренә кертелгән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары тарафыннан, шулай ук суд тарафыннан гамәлдән чыгарылырга яисә вакытлыча туктатылырга мөмкин; ә җирле үзидарә органнары тарафыннан аларга федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны көйли торган өлешендә — Россия Федерациясенең вәкаләтле дәүләт хакимияте органы (Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт хакимияте органы) тарафыннан да гамәлдән чыгарылырга яисә вакытлыча туктатылырга мөмкин.

   Норматив характерда булмаган муниципаль хокукый актның кануны (эше) — Россия Федерациясенең эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтлеләре турындагы законнарына ярашлы рәвештә бирелгән, Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле затның тиешле күрсәтмәсе (предписаниесе) алынган очракта, аны кабул иткән (чыгарган) җирле үзидарә органы яисә җирле үзидарә вазыйфаи заты тарафыннан кичекмәстән вакытлыча туктатыла. Җирле үзидарәнең башкарма-бөерү органнары яисә җирле үзидарә вазыйфаи затлары алынган күрсәтмәнең үтәлеше турында Россия Федерациясе Президенты каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле затка өч көнлек срокта, ә җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары үзләре карар кабул иткән көннән башлап өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә бурычлы.

2. Суд карары буенча «“Лаеш муниципаль районы” муниципаль берәмлеге һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләр территорияләренең чикләрен билгеләү һәм статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 28-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының гамәлдә булмавын тану, муниципаль берәмлек статусын билгеләү турында яңа закон үз көченә кергәнчегә кадәр, суд тәртибендә күрсәтелгән муниципаль берәмлекнең суд карары законлы көченә кергәнчегә кадәр кабул ителгән муниципаль хокукый актларын гамәлдә булмавын тану яисә әлеге муниципаль хокукый актларны гамәлдән чыгару өчен нигез булып тора алмый.

## XII бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ИКЪТИСАДИ НИГЕЗЕ

### 73 нче статья. Авыл җирлегенең икътисади нигезе

1. Авыл җирлегенең муниципаль милкендә булган мөлкәт, авыл җирлеге бюджеты акчалары, шулай ук авыл җирлегенең мөлкәти хокуклары авыл җирлегенең икътисади нигезен тәшкил итә.

### 74 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәте

1. Авыл җирлеге милкендә түбәндәге мөлкәт булырга мөмкин:

*1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы белән билгеләнгән авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен чишү өчен билгеләнгән мөлкәт;*

*2. федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларда җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 нче статьясының 4 нче өлешендә күздә тотылган тәртиптә җирле үзидарә органнарына бирелгән аерым вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт;*

*3. авыл җирлеге Советының норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының һәм вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр хезмәткәрләренең эшчәнлеген тәэмин итү өчен билгеләнгән мөлкәт;*

*4. чишү хокукы федераль законнар белән җирле үзидарә органына бирелгән һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләргә кертелмәгән мәсьәләләрне чишү өчен кирәкле мөлкәт;*

5. *«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясының 3 һәм 4 нче өлешләренә ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү өчен билгеләнгән мөлкәт, шулай ук «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 нче статьясының 1 һәм 1.1 өлешләренә ярашлы рәвештә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән мөлкәт.*
2. Авыл җирлеге милкендә авыл җирлекләренең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен чишү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле башка мөлкәт тә булырга мөмкин.

**75 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтенә ия булу, аннан файдалану һәм эш итү**

1. Җирле үзидарә органнары авыл җирлеге исеменнән Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга һәм аларга ярашлы рәвештә кабул ителә торган авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына нәтиҗәдә муниципаль мөлкәткә мөстәкыйль рәвештә ия булалар, аннан файдаланалар һәм аңа эш итәләр.
2. Җирле үзидарә органнары федераль законнарга ярашлы рәвештә муниципаль мөлкәтне физик һәм юридик затларга, Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына вакытлыча яисә даими файдалануга бирергә, аны читкә юнәлтергә, башка килешүләр төзергә хокуклы.
3. Җирле үзидарә органнары Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль мөлкәт реестрларын алып баралар.

**76 нчы статья. Муниципаль предприятиеләр, учреждениеләр һәм хуҗалык җәмгыятьләре**

1. Авыл җирлеге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне чишү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр төзи, аларны үзгәртеп кора һәм бетерә, хуҗалык җәмгыятьләре, шул исәптән муниципальара хуҗалык җәмгыятьләре төзүдә катнаша ала. Муниципаль предприятиеләргә һәм учреждениеләргә карата оештыручы (учредитель) функцияләрен һәм вәкаләтләрен җирле үзидарәнең вәкаләтле органнары гамәлгә ашыра.
2. Оештыручы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнары муниципаль предприятиеләр һәм учреждениеләр эшчәнлегенең

максатларын, шартларын һәм тәртибен билгелиләр, уставларын раслыйлар, әлеге предприятиеләр һәм учреждениеләр җитәкчеләрен вазыйфага билгелиләр һәм вазыйфадан азат итәләр, әлеге Уставта һәм муниципаль хокукый актларда күздә тотылган тәртиптә аларның эшчәнлеге турындагы хисапларын тыңлыйлар.

3. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары авыл җирлеге исеменнән муниципаль казна учреждениеләренең йөкләмәләре буенча субсидиар җаваплылык йөртәләр һәм федераль законда билгеләнгән очракларда һәм тәртиптә аларның үтәлешен тәэмин итәләр.
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләт биргән федераль башкарма хакимият органы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә муниципаль мөлкәт реестрын алып бара.

### 77 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары

1. Муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары федераль законнар нигезендә авыл җирлеге Советы карарлары белән билгеләнә.
2. Муниципаль мөлкәттән файдаланудан һәм аны хосусыйлаштырудан алынган керемнәр авыл җирлеге бюджетына керә.

### 78 нче статья. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр һәм оешмалар белән мөнәсәбәтләре

Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль милектә булмаган предприятиеләр, учреждениеләр, оешмалар, шулай ук физик затлар белән мөнәсәбәтләре, әгәр законнарда башкасы билгеләнмәгән булса, шартнамә нигезендә корыла.

## XIII бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ФИНАНС НИГЕЗЕ

### 79 нчы статья. Авыл җирлеге бюджеты

1. Авыл җирлегенең үз бюджеты бар.
2. Авыл җирлеге бюджеты авыл җирлеге Советының муниципаль норматив хокукый акты формасында эшләнелә һәм раслана.
3. Авыл җирлеге бюджетында авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрен чишү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга юнәлдерелә торган керемнәр һәм авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән бирелгән аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итү өчен бирелгән субвенцияләр, шулай ук күрсәтелгән керемнәр һәм субвенцияләр исәбенә гамәлгә ашырыла торган авыл җирлеге бюджетының тиешле чыгымнары аерым-аерым күздә тотыла.
4. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары, федераль законнарда һәм аларга ярашлы рәвештә кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив

хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, федераль дәүләт хакимияте органнарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында хисаплар тәкъдим итәләр.

### 80 нче статья. Авыл җирлегендә бюджет процессы

1. Авыл җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау, башкару һәм аның үтәлешен контрольдә тоту авыл җирлеге җирле үзидарә органнары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла. Авыл җирлеге бюджетын формалаштыру, раслау һәм башкару тәртибе Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, федераль законнар һәм аларга ярашлы рәвештә кабул ителгән Татарстан Республикасының Бюджет кодексы һәм Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнә.
2. Авыл җирлеге бюджеты проекты, авыл җирлеге Советының авыл җирлеге бюджетын раслау турындагы карары, аның үтәлеше турындагы еллык хисап, авыл җирлеге бюджетының башкарылу барышы турындагы кварталлык мәгълүматлар һәм җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең, муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең саны турындагы мәгълүматлар (аларның хезмәтенә түләүгә алынган фактик чыгымнарны күрсәтеп) рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткәрелергә) тиеш.
3. Авыл җирлеге бюджеты проекты өч еллык срокка (чираттагы финанс елы һәм планлы чор) төзелә һәм раслана.
4. Авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты проекты, авыл җирлегенең чыгым йөкләмәләрен финанс ягыннан тәэмин итү максатыннан, авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразы (прогнозы) нигезендә төзелә.
5. Авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты проекты, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм аның таләпләрен саклап кабул ителгән Татарстан Республикасының Бюджет кодексына һәм әлеге Уставка ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда төзелә.
6. Авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты проектын төзү түбәндәгеләргә нигезләнә:

   – Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Россия Федерациясендә бюджет сәясәтен (бюджет сәясәтенә карата таләпләрне) билгеләүче Юлламасы нигезләмәләренә;

   – Татарстан Республикасы Рәисенең Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Юлламасына;

   – Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аңа ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләүче документларга;

   – авыл җирлегенең бюджет сәясәтенең төп юнәлешләренә һәм салым сәясәтеннән төп юнәлешләренә;

   – авыл җирлегенең социаль-икътисади үсеш фаразына (прогнозына);

– озак вакытлы чорга бюджет фаразына (бюджет фаразы проектына, бюджет фаразына үзгәрешләр кертү проектына);

– дәүләт һәм муниципаль программаларга, дәүләт һәм муниципаль программалар проектларына, күрсәтелгән программаларга үзгәрешләр кертү проектларына;

– Россия Федерациясенең милли үсеш максатларын һәм аңа ирешү буенча ачык хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгеләүче документларга;

7. Авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты турындагы карарында бюджетның төп сыйфатламалары булырга тиеш, аларга бюджет керемнәренең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты, шулай ук Россия Федерациясенең Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы законнары, авыл җирлеге Советының муниципаль хокукый актлары (бюджет турындагы карардан тыш) белән билгеләнгән башка күрсәткечләр керә.
8. Авыл җирлеге бюджеты турындагы карар белән күрсәткечләр раслана, аларның составы Россия Федерациясенең Бюджет кодексына, аңа ярашлы рәвештә кабул ителгән Татарстан Республикасының Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы законнарына, район Советы карарларына ярашлы рәвештә билгеләнелә.
9. Чираттагы финанс елына һәм планлы чорга авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проекты расланган бюджетның планлы чоры параметрларын үзгәртү һәм аларга бюджет проектының планлы чоры икенче елының параметрларын өстәү юлы белән раслана.

   Чираттагы финанс елына һәм планлы чорга авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проекты расланган бюджетның планлы чоры күрсәткечләрен төгәлли һәм төзелә торган бюджетның планлы чоры икенче елының күрсәткечләрен раслый.

Авыл җирлегенең раслана торган бюджетының планлы чоры параметрларын төгәлләү түбәндәгеләрне күздә тота:

– авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты турындагы карар проектын карау предметы булып торган күрсәткечләрнең төгәлләмәләрен раслауны;

– авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасының расланган күрсәткечләрен арттыруны яисә кыскартуны раслауны яки аңа авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының өстәмә максатчан статьялары һәм (яисә) төрләре буенча бюджет ассигнованиеләрен кертүне.

10. Чираттагы финанс елына һәм планлы чорга авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проекты белән бер үк вакытта авыл җирлеге Советына түбәндәгеләр тәкъдим ителә:

    – авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләре;

– агымдагы финанс елының узган чоры өчен авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешенең якынча нәтиҗәләре һәм агымдагы финанс елында авыл җирлегенең социаль-икътисади үсешенең көтелмәгән (көтелгән) нәтиҗәләре;

– авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга социаль-икътисади үсеш фаразы;

– авыл җирлеге бюджетының чираттагы финанс елына һәм планлы чорга төп сыйфатламалары (керемнәрнең гомуми күләме, чыгымнарның гомуми күләме, бюджет дефициты) фаразы;

– авыл җирлеге бюджеты проектына аңлатма язмасы;

– бюджетлара трансфертларны бүлү методикалары (методикалар проектлары) һәм исәпләүләре;

– чираттагы финанс елы ахырына һәм планлы чорның һәр елы ахырына муниципаль бурычның чикке югары күләме;

– агымдагы финанс елына бюджетның көтелгән үтәлешен бәяләү;

– авыл җирлеге Советы тарафыннан тәкъдим ителгән күрсәтелгән органнарның бюджет сметалары проектлары (авыл җирлеге Башкарма комитеты белән күрсәтелгән бюджет сметаларына карата келешмәүчәнлекләр барлыкка килгән очракта тәкъдим ителә);

– Россия Федерациясенең Бюджет кодексы һәм аңа ярашлы рәвештә кабул ителгән Татарстан Republicсының Бюджет кодексы һәм әлеге Устав белән билгеләнгән башка документлар һәм материаллар.

Бюджет турындагы карар белән бюджет ассигнованиеләрен муниципаль программалар һәм программадан тыш эшчәнлек юнәлешләре буенча бүлү расланган очракта, бюджет турындагы карар проектына муниципаль программаларның паспортлары тәкъдим ителә.

Бюджет турындагы карар проектында бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта булмаган очракта, бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бюджет ассигнованиеләрен бүлү белән кушымта бюджет турындагы карар проектына аңлатма язмасы кушымталары составына кертелә.

11. Авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты проектын төзү, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына, федераль законнарга, аларга ярашлы рәвештә кабул ителә торган Татарстан Республикасының Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы законнарына ярашлы рәвештә, авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

12. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлегенең чираттагы финанс елына һәм планлы чорга бюджеты турындагы карар проектын авыл җирлеге Советы каравына агымдагы елның 15 ноябрендәгн дә соңга калмыйча кертә.

13. Авыл җирлеге Советының муниципаль норматив хокукый акты белән билгеләнгән авыл җирлеге бюджеты турындагы карар проектын карау һәм аны раслау тәртибе бюджет турындагы карарның чираттагы финанс елының 1 гыйнварыннан үз көченә керүен, шулай ук күрсәтелгән карар белән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 184.1 статьясына ярашлы рәвештә күрсәткечләрне һәм сыйфатламаларны раслауны күздә тотарга тиеш.
14. Авыл җирлеге бюджеты турындагы карар, әгәр Россия Федерациясенең Бюджет кодексында һәм (яисә) авыл җирлеге бюджеты турындагы карарда башкасы күздә тотылмаган булса, 1 гыйнвардан үз көченә керә һәм финанс елының 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
Авыл җирлеге бюджеты турындагы карар билгеләнгән тәртиптә аңа кул куелганнан соң ун көннән дә соңга калмыйча рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткәрелергә) тиеш.
15. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнары авыл җирлеге бюджетының балансланган булуын, бюджет хокук мөнәсәбәтләрен көйләү, бюджет процессын гамәлгә ашыру, дефицит күләме, муниципаль бурычның күләме һәм структурасы, авыл җирлегенең бюджет йөкләмәләрен үтәү буенча билгеләнгән федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләренең саклануын тәэмин итәләр.
16. Авыл җирлеге бюджеты керемнәре Россия Федерациясенең бюджет законнарына, салымнар һәм җыемнар турындагы законнарына һәм башка мәҗбүри түләүләр турындагы законнарына ярашлы рәвештә формалаша.
17. Авыл җирлеге бюджеты чыгымнары Россия Федерациясенең Бюджет кодексында күздә тотылган формаларда гамәлгә ашырыла.
18. Федераль дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен финанслауга авыл җирлеге бюджеты çыгымнарын юнәлдерү, федераль законнарда һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән очракларны исәпкә алмыйча, рөхсәт ителми.
19. Муниципаль мөлкәт объектларына бюджет инвестицияләре Россия Федерациясенең Бюджет кодексына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.

**81 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль ихтыяҗларын тәэмин итү өчен сатып алулар**

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу «Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өлкәсендә товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу буенча контракт системасы турында» 2013 елның 05 майдагы 44-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.
2. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу авыл җирлеге бюджеты акчалары исәбенә гамәлгә ашырыла.

### 82 нче статья. Авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчалары

1. Гражданнарның үзара салым акчалары дип җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне чишү өчен гамәлгә ашырыла торган гражданнарның бертапкырлык түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме абсолют зурлыкта авыл җирлегенең (авыл җирлеге составына керүче торак пунктның) барлык халкы өчен тигез итеп билгеләнә, аерым категория гражданнар моннан чыгарма булып тора (аларның саны авыл җирлеге (авыл җирлеге составына керүче торак пунктның) гомуми халкы саныннан 30 проценттан артып китә алмый һәм алар өчен түләүләр күләме киметелергә мөмкин).
2. Әлеге статьяның 1 нче өлешендә күрсәтелгән гражданнарның бертапкырлык түләүләрен кертү һәм аннан файдалану мәсьәләләре җирле референдумда, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясының 1 нче өлешенең 4.1 пунктында күздә тотылган очракта — гражданнар җыенында чишелә.

### 83 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль бурычы

1. Авыл җирлеге, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына һәм әлеге Уставка ярашлы рәвештә, муниципаль заемнар гамәлгә ашырырга, шул исәптән муниципаль кыйммәтле кәгазьләр чыгару юлы белән, хокуклы.
2. Авыл җирлеге исеменнән муниципаль заемнарны гамәлгә ашыру хокукы, Россия Федерациясенең Бюджет кодексына ярашлы рәвештә, җирлекнең Башкарма комитетына карый.

### 84 нче статья. Авыл җирлегенең җирле бюджетын башкару

1. Авыл җирлегенең җирле бюджетын башкару Россия Федерациясенең Бюджет кодексына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.
2. Авыл җирлеге бюджеты касса бердәмлеге һәм чыгымнарның ведомство карамагында булуы (подведомственность) нигезендә башкарыла.
3. Авыл җирлеге бюджеты үтәлешенә касса хезмәте күрсәтү, авыл җирлеге бюджеты акчаларын алучыларның шәхси счетларын ачу һәм алып бару Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.
4. Авыл җирлеге бюджетын башкару авыл җирлегенең җыелма бюджет язмасы (росписе) һәм авыл җирлегенең касса планы нигезендә оештырыла.

### 85 нче статья. Бюджет хисаплылыгы. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап

1. Авыл җирлегенең бюджет хисаплылыгы еллык булып тора.

2. Авыл җирлегенең бюджет хисаплылыгы, бюджет акчаларының тиешле баш администраторларының җыелма бюджет хисаплылыгы нигезендә, авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан төзелә.
3. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап авыл җирлеге Советы карары белән расланырга тиеш.
4. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап, авыл җирлеге Советына тәкъдим ителгәнчегә кадәр, тышкы тикшерү узарга тиеш, ул бюджет акчалары баш администраторларының бюджет хисаплылыгына тышкы тикшерү үткәрүне һәм авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә (заключение) әзерләүне үз эченә ала.

   Авыл җирлеге Советы мөрәҗәгате буенча «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Никольский  авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапка тышкы тикшерү Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5. Авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисапны, аңа бәяләмә әзерләү өчен, агымдагы финанс елының 1 апреленнән дә соңга калмыйча тәкъдим итә. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә әзерләү, бюджет акчалары баш администраторларының еллык бюджет хисаплылыгын тышкы тикшерү мәгълүматлары нигезендә, 1 айдан артып китми торган срокта үткәрелә.
6. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапка бәяләмә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Контроль-хисап палатасы тарафыннан авыл җирлеге Советына тәкъдим ителә һәм бер үк вакытта авыл җирлеге Башкарма комитетына җибәрелә.
7. 7. Ел саен агымдагы финанс елының 1 маеннан да соңга калмыйча, авыл җирлеге Башкарма комитеты авыл җирлеге Советына хисап елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны, аңа раслау рәвешендә авыл җирлеге Советының хисап елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турында карары проектын, авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турындагы башка бюджет хисаплылыгын һәм Россия Федерациясенең бюджет законнарында күздә тотылган башка документларны теркәп тәкъдим итә.
8. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны карау нәтиҗәләре буенча авыл җирлеге Советы авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисапны раслау яисә кире кагу турында карар кабул итә.

   Авыл җирлеге Советы тарафыннан авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы еллык хисап кире кагылган очракта, ул мәгълүматларның дөрес булмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын бетерү һәм 1 айдан артып китми торган срокта кабат тәкъдим итү өчен кире кайтарыла.

9. Авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы карар белән авыл җирлеге бюджеты керемнәренең, чыгымнарының гомуми күләмен һәм авыл җирлеге бюджеты дефицитын күрсәтеп, хисап елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы хисап раслана.

Авыл җирлеге Советының хисап елы өчен авыл җирлеге бюджетының үтәлеше турындагы карарына аерым кушымталар белән түбәндәге күрсәткечләр раслана:

– бюджетлар керемнәре классификациясе кодлары буенча авыл җирлеге бюджеты керемнәре;

– авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

– бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча авыл җирлеге бюджеты чыгымнары;

– бюджетлар дефицитын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча авыл җирлеге бюджеты дефицитын финанслау чыганаклары.

### 86 нче статья. Авыл җирлегенең муниципаль финанс контроле

1. Муниципаль финанс контроле Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан физик затларга массакүләм норматив йөкләмәләрне һәм башка түләүләр буенча йөкләмәләрне шартлаучы (билгеләүче) хокукый актлар нигезләмәләренең саклануын, шулай ук дәүләт (муниципаль) контрактларының, бюджеттан акча бирү турындагы шартнамәләрнең (килешүләрнең) шартлары үтәлешен тәэмин итү максатыннан гамәлгә ашырыла.
2. Тышкы муниципаль финанс контроле ТР Лаеш муниципаль районының Контроль-хисап палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.
3. Эчке муниципаль финанс контроле Федераль казначылыкның, ТР Лаеш муниципаль районының Финанс-бюджет палатасының контроль эшчәнлеге булып тора.
4. Алдан карый торган (предварительный) контроль авыл җирлегенең җирле бюджетын башкару барышында бюджет хокук бозуларын кисәтү һәм аларга чик кую максатында гамәлгә ашырыла.
5. Алдагы (последующий) контроль, аларның башкарылуының законлылыгын, исәп-хисап һәм хисаплылыкның дөреслеген билгеләү максатында, авыл җирлеге бюджетының үтәлеше нәтиҗәләре буенча гамәлгә ашырыла.

## XIV бүлек. АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ УСТАВЫН КАБУЛ ИТҮ. ӘЛӘГЕ УСТАВКА ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕРТҮ

### 87 нче статья. Авыл җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү проектын әзерләү тәртибе

1. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы авыл җирлеге Советы карары проекты авыл җирлеге Советына авыл җирлеге Башлыгы, авыл җирлеге Советы депутатлары, территория җирле үзидарә органнары, гражданнарның инициативалы төркемнәре тарафыннан кертелергә мөмкин.
2. Авыл җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турында карар проектын әзерләү өчен, авыл җирлеге Советы карары белән махсус комиссия

төзелергә мөмкин. Күрсәтелгән комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары белгечләре, экспертлар чакырылырга мөмкин.

3. Авыл җирлеге Уставы проекты, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты, авыл җирлеге Уставын кабул итү, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү мәсьәләсен карау көненә кадәр 30 көннән дә соңга калмыйча, авыл җирлеге Советы тарафыннан билгеләнгән күрсәтелгән Устав проекты, күрсәтелгән муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аңа карата фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен бер үк вакытта бастырып чыгару (халыкка җиткерү) белән рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга (халыкка җиткәрелергә) тиеш. Әлеге Уставны норматив хокукый актларга туры китерү максатыннан, авыл җирлеге Уставына Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе (Уставы) яисә законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгән очракта, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проекты буенча тәкъдимнәрне исәпкә алу тәртибен, шулай ук аңа карата фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен рәсми рәвештә бастырып чыгару (халыкка җиткерү) таләп ителми.
4. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында авыл җирлеге Советы карары проекты буенча, аларны авыл җирлеге Советы утырышында караганчы, әлеге Уставка ярашлы рәвештә ачык тыңлаулар үткәрелә, әлеге Уставны норматив хокукый актларга туры китерү максатыннан, Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе (Уставы) яисә законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау формасында үзгәрешләр кертелгән очраклар моннан чыгарма булып тора.

5. Авыл җирлеге Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү әлеге закон чыгару актларында билгеләнгән срокта гамәлгә ашырыла. Федераль законда, Татарстан Республикасы законында күрсәтелгән срок билгеләнмәгән очракта, авыл җирлеге Уставын федераль законга, Татарстан Республикасы законына туры китерү срогы тиешле федераль законның, Татарстан Республикасы законының үз көченә керү датасын, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт проектын рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) һәм ачык тыңлауларда карау кирәклеген, ул проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алуны, авыл җирлеге Советы утырышларының периодиклыгын, мондый муниципаль хокукый актны дәүләт теркәве узу һәм рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) срокларын исәпкә алып билгеләнә һәм, кагыйдә буларак, алты айдан артып китәргә тиеш түгел.

6. Авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт белән авыл җирлеге Уставын яңа редакциядә бәян итүгә рөхсәт ителми. Бу очракта авыл җирлегенең яңа Уставы кабул ителә, ә элек гамәлдә булган авыл җирлеге Уставы һәм аңа үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актлар яңа авыл җирлеге Уставы законлы көченә кергән көннән башлап үз көчен югалткан дип таныла.

**88 нче статья. Авыл җирлеге Уставын кабул итү, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү тәртибе**

1. Авыл җирлеге Уставы проектын, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карар проектын карау авыл җирлеге Советы тарафыннан, авыл җирлеге Советы Регламентына ярашлы рәвештә, икедән дә ким булмаган укылышта гамәлгә ашырыла.
2. Авыл җирлеге Уставы проекты, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карар проекты беренче укылышта кабул ителгәннән соң, күрсәтелгән проект авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан авыл җирлеге Советы депутатларына, хокук чыгару башлангычы хокукының башка субъектларына төзәтмәләр кертү өчен җибәрелә.
3. Авыл җирлеге Уставы, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертү турындагы авыл җирлеге Советы карары авыл җирлеге Советы депутатларының билгеләнгән санының өчтән ике өлеше күпчелек тавышы белән кабул ителә.

**89 нчы статья. Авыл җирлеге Уставының, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы карарның законлы көченә керү тәртибе**

1. Авыл җирлеге Уставы, авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы авыл җирлеге Советы карары, алар кабул ителгәннән соң, федераль законда билгеләнгән тәртиптә дәүләт теркәве узу өчен, авыл җирлеге Башлыгы тарафыннан муниципаль берәмлекләр уставларын теркәү өлкәсендә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органына җибәрелә.
2. Авыл җирлеге Уставы, әлеге Уставка үзгәрешләр кертү турындагы авыл җирлеге Советы карары, алар дәүләт теркәве узганнан соң, рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткәрелергә) тиеш һәм рәсми бастырып чыгарылганнан (халыкка җиткәрелгәннән) соң законлы көченә керәләр.

   Авыл җирлеге башлыгы теркәлгән муниципаль берәмлек уставын, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турындагы муниципаль хокукый актны — муниципаль берәмлек уставы, муниципаль берәмлек уставына үзгәрешләр кертү турындагы муниципаль хокукый акт турындагы мәгълүматларны Россия Федерациясе субъектының муниципаль берәмлекләре уставлары дәүләт реестрына кертү турындагы хәбәрнамә алынган көннән башлап җиде көн дәвамында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) бурычлы; бу хәбәрнамә «Муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәве турында» 2005 елның 21 июлендәге 97-ФЗ номерлы Федераль законның 4 нче статьясының 6 нчы өлешендә күздә тотылган.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Никольский  авыл җирлеге башлыгы —**
**Совет рәисе** **А.Н.Пашагин**